ФГОС

Р. З. Хайдарова, Р. Л. Малафеева, Г. М. Ахметзянова

# ТАТАР ТЕЛЕ



## 7 класс

издательство
«Татармультфильм»

# Причастие
# Сыйфат фигыль

**Причастие (сыйфат фигыль) имеет признаки глагола и имени прилагательного, представляет собой глагольно-именную форму. В татарском языке причастие имеет три формы времени: настоящее, прошедшее, будущее.**

| | |
|---|---|
| **Хәзерге заман сыйфат фигыль** | **а) -учы/-үче**<br>**жырла-учы кыз (поющая девочка)**<br>**сөйлә-үче кеше (рассказывающий человек)**<br>**ә) -а/-ә+торган, -ый/-и+торган**<br>**бара торган кыз (идущая девочка)**<br>**бии торган малай (танцующий мальчик)** |
| **Үткән заман сыйфат фигыль** | **-ган/-гән, -кан/-кән**<br>**жырлан-ган жыр (спетая песня)**<br>**сөйлән-гән сүз (сказанное слово)**<br>**ярат-кан эш (любимая работа)**<br>**кит-кән кеше (ушедший человек)** |
| **Киләчәк заман сыйфат фигыль** | **а) -ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк**<br>**бар-ачак юл (предстоящая дорога)**<br>**кил-әчәк кеше (человек, который должен прийти)**<br>**жырла-ячак жыр (песня, которую предстоит спеть)**<br>**сөйлә-ячәк шигырь (стихотворение, которое предстоит рассказать)**<br>**ә) -ыр/-ер, -ар/-әр, -р**<br>**бар-ыр юл (дорога, по которой предстоит идти)**<br>**б) -асы/-әсе, -ыйсы/-исе**<br>**бар-асы юл (дорога, по которой предстоит идти)** |

# Деепричастие
# Хәл фигыль

**Деепричастие (хәл фигыль) в татарском языке имеет признаки глагола и наречия, обозначает добавочное действие, поясняющее как, когда, почему, с какой целью совершается основное действие.**

**Деепричастие образуется при помощи следующих аффиксов:**

| -ып<br>-еп<br>-п | -гач/-гәч<br>-кач/-кәч | -ганчы/-гәнче<br>-канчы/-кәнче | -а/-ә<br>-ый/-и |
|---|---|---|---|
| ал-ып (взяв)<br>кил-еп (придя)<br>аңла-п (понимая) | ал-гач (взяв, как только взял)<br>күр-гәч (увидев; как только увидел)<br>кайт-кач (вернувшись; как только вернулся)<br>әйт-кәч (сказав; как только сказал) | ал-ганчы (пока не возьмёт)<br>кил-гәнче (пока не придёт)<br>кайт-канчы (пока не вернётся)<br>кит-кәнче (пока не уйдёт) | кайта-кайта (возвращаясь)<br>сикерә-сикерә (прыгая)<br>уйлый-уйлый (думая)<br>сөйли-сөйли (говоря) |

Р. З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, Г. М. Әхмәтҗанова

# ТАТАР ТЕЛЕ

# 7

## ҖИДЕНЧЕ СЫЙНЫФ

ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(ТАТАР ТЕЛЕН БАШЛАП ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

ДӘРЕСЛЕК Е. И. ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ
НИГЕЗЛӘНӘ

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2025

**Р. З. Хайдарова, Р. Л. Малафеева, Г. М. Ахметзянова**

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

# 7

## СЕДЬМОЙ КЛАСС

**УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ ОСНОВНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ (ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ, НЕ ВЛАДЕЮЩИХ ТАТАРСКИМ ЯЗЫКОМ)**

**НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ Е. И. ПАССОВА**

**КАЗАНЬ**
**ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»**
**2025**

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я72
Х18

## Условные обозначения

Начало урока

Запомни!

Вспомни!

Произноси правильно!

Работа в парах

Работа в группах

Творческая работа

Инсценирование

Ситуативные упражнения

Посмеёмся вместе

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 7 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З. Хайдарова, Р.Л. Малафеева, Г.М. Ахметзянова. — Казань: Татармультфильм, 2025. — 126 с.: ил.

ISBN 978-5-906508-57-7

**ISBN 978-5-906508-57-7**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я72**

© Хайдарова Р.З., Малафеева Р.Л., Ахметзянова Г.М., 2025
© Издательство «Татармультфильм», 2025
Все права защищены

# БЕЛЕМ ҺӘМ ТОРМЫШ



## 1–3 нче дәресләр



**1.** Диалоглар кайсы рәсемнәргә туры килә?

1. — Сәлам, Илшат!
— Сәлам, Юра!
— Илшат, син ничәнче сменада укыйсың?
— Икенче сменада.



2.— Исәнмесез, Римма Идрисовна! Бәйрәм белән сезне! Бу чәчәкләр сезгә безнең сыйныфтан.
— Рәхмәт. Сезне дә яңа уку елы белән котлыйм! Сезгә уңышлар телим!



3.— Әни, әйдә тизрәк, соңга калабыз.
— Юк, кызым, линейка башланмады әле.

**2.** Схемалар буенча нинди диалоглар төзи аласыз? Уйлап карагыз.

1) — сәламләү
— сәламләү
— комплимент, сорау
— җавап

2) — комплимент, сорау
— җавап, сорау
— җавап, сорау
— җавап

**3.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнегез.

**Хуш килдең, беренче сентябрь!**

Хуш килдең, беренче сентябрь,
Әйдә, кер мәктәпкә, көлеп кер!
Күңелле көн бүген, җырлы көн,
Кояшлы көн бүген, нурлы көн!

Х. Шакиров

**4.** Сезнең мәктәптә беренче сентябрь ничек узды? Көн нинди иде? Кечкенә хикәя төзегез, сөйләргә әзерләнегез.

**5.** Яңа уку елына әзерлек, нинди уку-язу әсбаплары алуыгыз турында бер-берегез белән сөйләшегез.

**6.** Диалогны укыгыз, сөйләшеп карагыз.

— Хәерле көн, Настя!
— Исәнме, Илнар!
— Илнар, син татар теленнән өй эшен эшләдеңме?
— Әйе, эшләдем, кагыйдәләрне дә кабатладым.
— Димәк, син бүген бишле аласың инде?
— Тырышып карыйм.
— Карале, Илнар, синең сумкаң бик матур! Яңа сумка алдыгызмы әллә?
— Әйе, апам бүләк итте.

**7.** Бирелгән сүзләрдән сыйфатлар ясагыз.

| | **-лы/-ле** | **-сыз/-сез** |
|---|---|---|
| күңел | күңелле | күңелсез |
| җил | ... | ... |
| кояш | ... | ... |
| яңгыр | ... | ... |
| болыт | ... | ... |

**8.** Рәсемнәргә карагыз һәм:

а) рәсемнәргә туры килгән сүзтезмәләрне әйтегез;
ә) сүзтезмәләрне кулланып, сораулар уйлагыз;
б) диалоглар төзеп сөйләшегез.








С ү з т е з м ә л ә р: көзге көн; җилле көн; күңелсез көн; салкын көн; кояшлы көн; яңгырлы көн.

## 4–5 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәргә карап, **кайда?** соравына җавап бирегез. Сез кайда ял иттегез?






**-да/-дә**
**-та/-тә**






**2.** Диалогларны укыгыз. Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне языгыз.

1. — Җәйге каникуллар ничек үтте?

— Яхшы. Мин  булдым.

— Ничек ял иттең?

— Төрлечә. Велосипедта йөрдем, кызындым, су коендым, дачада ял иттем, әниләргә булыштым. Ә син?

— Ә мин  булдым.

2. — Саша, мин сине июль аенда күрмәдем. Син кайда идең?

— Июль аенда без  булдык. Анда шундый күңелле.

3. — Дима, син каникулда кайда булдың? Ничек ял иттең?

— Без гаиләбез белән  булдык. Беренче тапкыр самолётта очтым.
— Ничек соң, куркынычмы?
— Юк, бар да әйбәт булды.

4. — Лена, җәйләр ничек узды?

— Искиткеч күңелле булды. 

лагеренда булдым.

**3.** Таблицадагы фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртегез.

| Боерык фигыль | Билгеле үткән заман хикәя фигыль | | Билгесез үткән заман хикәя фигыль | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлык | Юклык | Барлык | Юклык |
| бар | барды | бармады | барган | бармаган |
| ял ит | ... | ... | ... | ... |
| булыш | ... | ... | ... | ... |
| кайт | ... | ... | ... | ... |
| йөз | ... | ... | ... | ... |
| кызын | ... | ... | ... | ... |

**4.** Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыльләрне кулланып, җәйге ялның ничек үтүе турында диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

5. Сообщите родителям, что:

— в вашей школе начал работать новый директор;
— вам раздали новые учебники;
— вы будете учиться в первую смену;
— ваш друг перешёл в другую школу;
— в ваш класс пришли два новых ученика;
— была встреча с известным писателем.

6. Схемалар буенча җәйге ял турында диалоглар төзегез.

1) — сәламләү
— сәламләү, сорау
— җавап, сорау
— җавап

2) — сорау
— җавап, сорау
— җавап, тәкъдим
— килешү

7. Ә сез җәйне ничек үткәрдегез? Кайда ял иттегез? Кечкенә хикәя төзегез.

8. Үзегез төзегән хикәяне бер-берегезгә сөйләгез.

## 6–8 нче дәресләр

1. **Исегезгә төшерегез!**

**Деепричастие (хәл фигыль)** имеет признаки глагола и наречия, обозначает каким образом, почему, когда совершается основное действие.

Дәресләрне **әзерләгәч**, урамга чыгам. — Выйду на улицу, когда сделаю уроки (сделав уроки).

Без мәктәптән **сөйләшә-сөйләшә** кайттык. — Мы шли из школы разговаривая.

Мәктәпкә **барганчы** ук, бер хәбәр ишеттек. — Услышали новость до того, как пришли в школу.

Укытучы кагыйдәне тактага **язып** аңлатты. — Учитель объяснил правило, написав на доске.

**2.** Изучите таблицу. На какие вопросы отвечает деепричастие? С помощью каких окончаний оно образуется?

| -п/<br>-ып/-еп | -а/-ә<br>-ый/-и | -гач/-гәч<br>-кач/-кәч | -ганчы/-гәнче<br>-канчы/-кәнче |
|---|---|---|---|
| яз-ып<br>сөйлә-п<br>сөйләш-еп<br>кайт-ып | яза-яза<br>сөйли-сөйли<br>сөйләшә-сөйләшә<br>кайта-кайта | яз-гач<br>сөйлә-гәч<br>сөйләш-кәч<br>кайт-кач | яз-ганчы<br>сөйлә-гәнче<br>сөйләш-кәнче<br>кайт-канчы |

**3.** Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез, хәл фигыльләрне билгеләгез.

1. Он на уроке всегда говорит шёпотом. 2. Долго думая, решаю задачу. 3. После сдачи экзамена начались каникулы. 4. До прихода мамы я смотрел по телевизору передачу «Новости».

**4.** Бирелгән фигыльләрдән хәл фигыльләр ясагыз. Алар белән җөмләләр төзегез.

Ү р н ә к: яз — язып, яза-яза, язгач, язганчы.
Укы, үзгәрт, файдалан, җавап бир.

**5.** Нокталар урынына тиешле аффиксларны өстәп языгыз.

1. Безнең сыйныфта 23 укучы, ләкин аларның унысы гына тырыш... укый. 2. Оля кил..., имтихан башланган иде. 3. Укытучы кил..., имтихан башланды. 4. Көндәлектә дүртле-бишлеләр күп бул..., миңа бик күңелле. 5. Мин җөмләне үзгәрт... яздым. 6. Тырыш... укы..., миңа имтиханнар бирү дә җиңел булды.

**6.** 5 нче күнегүдәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар языгыз, алар ярдәмендә үзара сөйләшегез.

**7.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Радуясь, я возвращался из школы домой.
2. Придя в школу, от друзей я узнал хорошую новость.
3. Я не делал домашнее задание, пока не получил двойку.

4. Когда человек достигает цели, он становится счастливым.
5. Изменив задание, ты правильно сделал.

**8.** Нокталар урынына тиешле хәл фигыльләрне өстәп языгыз.

1. Әни эштән ..., мин велосипедта йөрергә чыктым. 2. Җавапны дәфтәргә ..., тагын бер тапкыр тикшерергә кирәк. 3. Дустым мине ... сәламләде. 4. «... укы, шул вакытта теләгәнеңә ирешерсең», — ди миңа әтием.

С а й л а п  а л у  ө ч е н: тырышып, күргәч, язганчы, кайткач.

**9.** Җөмләләрдән хәл фигыльләрне табыгыз, аффиксларны билгеләгез, аларга сораулар куегыз.



Мин иртән, йөгерә-йөгерә, мәктәпкә бардым. Кибетне үткәч, Айгөлне очраттым. Айгөл мәктәпкә зур чәчәк бәйләме тотып бара. Без мәктәпкә кадәр сөйләшә-сөйләшә бардык. Бүген сыйныф җитәкчебезнең туган көне икән! Укытучыбыз килгәнче, чәчәкләрне вазага утыртып, өстәл уртасына куйдык. Менә кыңгырау шалтырады. Без, ашыга-ашыга, үз парталарыбызга утырдык. Сыйныф бүлмәсенә Мария Ивановна керде, елмаеп, чәчәкләргә карады. Без дә елмайдык. Бик күңелле булды.

**10.** Рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.







**11.** Как скажете о том, что вы:

— разговаривая шли в школу;
— спеша поели суп;
— улыбаясь поздоровались;
— до прихода гостей убрались дома?

**12.** 9 нчы күнегүдәге текст эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**13.** Һәр көнне иртән сине мәктәптә укытучы каршы ала. Ул — синең тормышыңда бик мөһим кеше. Укытучы сиңа белем һәм тәрбия бирә. 5 нче октябрьдә бик матур бәйрәм — Укытучылар көне билгеләп үтелә. Укытучыларга бәйрәм белән котлау языгыз.




## 9–11 нче дәресләр

**1.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

**встал рано**
1) иртүк уянам 2) иртә тордым 3) иртән уяндым

**хорошенько поел**
1) яхшы ашадым 2) яхшылап ашадым

**в этом году**
1) узган ел 2) быел 3) былтыр

**2.** Хикәяне укыгыз. Хикәядә сүз нинди көн турында бара?

Бу көнне мин һәрвакыт көтеп алам. Ни өчен? Чөнки мин, җәйге ялдан соң, сыйныфташларым белән очрашам. Шуңа күрә мин бүген иртә тордым. Торгач юындым, тәмләп ашадым һәм яңа формамны кидем. Сумкамны бик җиңел иде, чөнки әле дәреслекләр юк. Аларны бүген мәктәпкә баргач бирәчәкләр.

Мәктәпкә бара-бара, мин дусларымны искә төшердем. Әнә алар да, сөйләшә-сөйләшә, мәктәпкә баралар. Без, мәктәпкә барганчы ук, яңа сыйныф җитәкчесе турында белдек. Ә мәктәпкә килгәч, тагын бер хәбәр ишеттек: яңа директор киләчәк.

**хәбәр** — весть, новость
**искә төшердем** — вспомнил

**3.** Сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз.

Соң, белән, шуңа күрә, һәрвакыт, иң, ләкин, әле, юк, да.

**4.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

Торгач юындым, тәмләп ашадым һәм яңа формамны кидем. Без, мәктәпкә барганчы ук, яңа сыйныф җитәкчесе турында белдек. Сумкамны бик җиңел иде, чөнки әле дәреслекләр юк. Бу көнне мин һәрвакыт көтеп алам. Ә мәктәпкә килгәч, тагын бер хәбәр ишеттек: яңа директор киләчәк.

**5.** Хикәядәге фигыльләрне төрле заманнарга куегыз, таблицага языгыз.

| Хәзерге заман | Үткән заман | Киләчәк заман |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

**6.** Хикәядәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча, хәл фигыльләрне кулланып, сораулар уйлагыз, үзара сөйләшегез.

Үрнәк: — Мәктәпкә баргач, нәрсәләр бирәчәкләр?
— Мәктәпкә баргач, дәреслекләр бирәчәкләр.

**7.** Хикәянең эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**8.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп языгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

1. — ... ?
— Мин иртән торгач, зарядка ясыйм.
— ... ?
— Иртән сумкамны карыйм, уку әсбапларымны тикшерәм.

2. — Алмаз, нигә кире кайттың?
— Китапны оныттым.
— ... ?
— Өстәл өстендә иде.

**9.** Диалог эчтәлеге буенча үзара сөйләшегез.

— Хәерле көн, Алмаз!
— Хәерле көн, Миша!
— Бүген урамда нинди матур көн, дәрестән соң уйнарга чыгасыңмы?
— Дәресләрне әзерләп бетергәч, әлбәттә, чыгам.
— Нинди уеннар уйныйбыз?
— Футбол, волейбол.
— Бу уеннар миңа да ошый.
— Дуслар да чыгамы?
— Коля, Дамир чыга.
— Алайса кичкә кадәр.
— Сау бул.

**10.** Посоветуйте сестрёнке:

— вставать рано;
— убирать постель;
— не разговаривать на перемене громко;
— перед уходом в школу проверять сумку;

— старательно учиться по всем предметам;
— не разговаривать на уроке даже шёпотом;
— внимательно слушать учителя;
— вовремя выполнять домашнее задание.

**11. Исегездә калдырыгыз!**

**мәктәп** — школа **китапханә** — библиотека
**мәктәп китапханәсе** — школьная библиотека

**мәктәп** — школа **бакча** — сад (огород)
**мәктәп бакчасы** — школьный сад (огород)

**12.** Ике исемнән яңа сүзтезмә ясагыз. Җөмләләр төзегез.

математика, дәрес — ...
рус теле, дәрес — ...
җыр, дәрес — ...
татар теле, укытучы — ...
татар теле, дәреслек — ...
Әлмәт, шәһәр — ...
сыйныф, җитәкче — ...
рус, мәктәп — ...
мәктәп, директор — ...
Казан, гимназия — ...

## 12–13 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Глаголы повелительного наклонения (боерык фигыльләр)** выражают просьбу, повеление, приказ совершить какое-либо действие и имеют формы второго и третьего лица единственного и множественного числа.

**Боерык фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше**
Спряжение глаголов повелительного наклонения

Барлык формасы
Положительная форма

**Берлек санда**

I —
II (син) бар — (ты) иди
III (ул) бар-**сы́н** — (он) пусть идёт

**Күплек санда**

I —
II (сез) ба́р-**ыгыз** — (вы) идите
III (алар) бар-**сын-на́р** — (они) пусть идут

Ярдәмгә — плакатлар!

Юклык формасы
Отрицательная форма

**Берлек санда**

I —
II (син) ба́р-ма — (ты) не иди
III (ул) ба́р-ма-**сын** — (он) пусть не идёт

**Күплек санда**

I —
II (сез) ба́р-ма-**гыз** — (вы) не идите
III (алар) ба́р-ма-**сын-нар** — (они) пусть не идут

**2. Исегезгә төшерегез!**

Во втором лице множественного числа положительной формы, а также во втором и третьем лице единственного и множественного числа отрицательной формы глагола повелительного наклонения ударение падает на первый слог слова.

**3.** Боерык фигыльләргә басымнарны дөрес куеп, җөмләләрне укыгыз. Тәрҗемә итегез.

1. Беркем дә икеле алмасын. 2. Язма эштә Олег хата ясамасын. 3. Һәркем максатына ирешсен. 4. Һәркем татар телен яхшы белсен. 5. Ул бүген безгә килмәсен. 6. Дамир Оляга китапны бирмәсен. 7. Зинһар, бу конфетларны кечкенә сеңлем күрмәсен. 8. Бүлмәгә беренче булып Олег керсен. 9. Башта зурлар утырсын.

**4.** Тәрҗемә итегез. Фигыльләрнең басымын билгеләгез:

— пусть сегодня ко мне придёт мой друг;
— пусть Маша вечером зайдёт к бабушке;
— пусть Роза узнает об этом.

**5.** Диалоглардан боерык фигыльләрне табыгыз, затларын билгеләгез.

1. — Әни, безгә Оля килсен әле!
— Ярый, мин риза. Килсен. Сез бездә нишлисез?
— Дәрес әзерлибез. Математикадан мәсьәлә бик авыр.
— Абыең булышсын.
— Юк, без үзебез чишәбез.
— Ярый. Аннан соң саф һавага чыгыгыз.

2. — Надя, миңа булыш әле.
— Нәрсә эшләргә?
— Мәсьәлә чишәргә.
— Эшем күп, абыең булышсын.
— Абый өйдә юк.
— Ярый, ярты сәгатьтән киләм, көт.

**6.** 5 нче күнегүдәге диалогларны үзара сөйләшергә өйрәнегез.

**7.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез. Алар сезгә бер кызык шигырьне аңларга ярдәм итәр.

Алдына, китабын, кайткач, тышы, коелып, яткач, өскә, сансыз, беркем.

**8.** Нокталар урынына 7 нче күнегүдәге сүзләрне куеп языгыз.

1. Яраткан китабымның ... пычранды. 2. Бу китапның битләре ... төшкән. 3. Вова бүген ... алып килергә оныткан. 4. Өйгә ..., рәхәтләнеп яраткан китабымны укыдым.

**9.** Фигыльләрне үрнәк буенча үзгәртегез.

Ү р н ә к: бара — бар — барсын — бармасын.

Китерә, күрә, төшә, бетә, коела, сөйли, кайта, укый, ята, ата, бирә.

**10.** Нокталар урынына тиешле аффиксларны куегыз.

Мин китапханә... килдем.
Мин китапханә... китап укыйм.
Мин китапханә... китап алдым.

**11.** Шигырьне укыгыз. Саматның китапка мөнәсәбәте (отношение) сезгә ошыймы?

**Самат**

Алдына гына карап,
Китабын суза Самат.
Ул да китап китергән,
Һай, бу китап ни күргән!
Тышы төшкән суелып,
Эче беткән коелып.
Ни булды? Менә кызык:
Телгә килде бу китап.
Әй сөйли, кызып-кызып:
— Өенә алып кайткач,
Кич бераз укып яткач,
Мине селтәп атты, — ди, —
Өскә менеп ятты, — ди, —
Һай, минем күргәннәрне
Бер китап та күрмәсен.
Андый сансыз малайга
Беркем китап бирмәсен.

З. Туфайлова





**суелып төшкән** — содрана
**эче коелып беткән** — страницы выпали
**телгә килде** — заговорила
**кызып-кызып** — возбуждённо
**селтәп атты** — выкинул
**сансыз** — здесь: непутёвый, безалаберный

**12.** План буенча шигырьне өлешләргә бүлеп укыгыз.

1. Самат китапханәдә.
2. Китапның кыяфәте.
3. Китапның күргәннәре.
4. Китапның теләкләре.

**13.** Җөмләләрдән фигыльләрне табыгыз, заманнарын билгеләгез. Җөмләләрне шигырь эчтәлеге эзлеклелегендә урнаштырыгыз һәм сөйләргә өйрәнегез.

1. Китапханәче апа Саматның китабына карады. 2. Самат китапны саклап тотмаган. 3. Самат мәктәп китапханәсенә килде. 4. Ул аны селтәп аткан, өстенә менеп яткан, теләсә кая ыргыткан. 5. Ул китапны тапшырырга теләде. 6. Китапханәче апага Самат ошамады. 7. Китап бик пычрак иде: аның тышы ертылып төшкән, эче коелган. 8. Саматка бик-бик кыен булды.

**14.** Как скажете:

— пусть Самат не читает книгу лёжа;
— пусть Самат не ложится на книгу;
— пусть Самат бережно относится к книге?

**15.** Диалогны дәвам итегез.

1\. — Самат, китабың бик пычрак, нәрсә булды?
— Китап белән кечкенә сеңлем уйнаган.
— Ул китап белән нәрсә эшләгән?
— ... .

2. — Син китап укырга яратасыңмы?
— Әйе, китап укырга яратам.
— Нәрсә турында укырга яратасың?
— … .

**16.** Әйтик, Самат — житди, игътибарлы, тәртипле малай. Саматның китапны саклап тотуы турында (о бережном отношении) кечкенә хикәя төзегез. Үзегез төзегән хикәяне сөйләргә өйрәнегез.

**17.** Елмаеп алыйк әле!



Укытучы:

— Балалар, «Кыз бала ял итә» дигән җөмләне языгыз, фигыльне табыгыз.

— Монда фигыль юк бит, апа, — ди бер укучы. — Фигыль «нәрсә эшли?» дигән сорауга җавап бирә, ә кыз бала бернәрсә дә эшләми, ял итә.

## 14–15 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Наречие (рәвеш)** — часть речи, которая обозначает признак действия (**тиз** йөгерә — **быстро** бежит) или обстоятельства, при котором происходит действие (**кичә** бардык — **вчера** ходили).

Ярдәмгә — плакатлар!

**2.** Җөмләләрне укыгыз, рәвешләрне табыгыз.

1. Ул мәктәпкә озак барды. 2. Малай бик әкрен укый. 3. Кичә кызыклы фильм булды. 4. Мин татарча сөйләшәм. 5. Ул мәсьәләне тиз чиште.

**3. Исегездә калдырыгыз!**

**Рәвеш төркемчәләре**
Разряды наречий по значению

**Саф рәвешләр (образа действия):** тиз, әкрен.

**Охшату-чагыштыру (сравнения, уподобления):** дусларча, кояштай.

**Күләм-чама (меры и степени):** шактый, бераз.

**Вакыт (времени):** быел, иртәгә.

**Урын (места):** ерак, якын, югары, түбән.

**Сәбәп (причины)** һәм **максат (цели):** юкка, тикмәгә.

**4.** Җөмләләрдән рәвешләрне табыгыз, төркемчәләрен билгеләгез.

1. Оля тиз генә өй эшен эшләде дә урамга чыкты. 2. Без татарча яхшы сөйләшәбез. 3. Мин бакчада бик озак эшләдем. 4. Иртәгә бездә математикадан контроль эш була. 5. Быел көз бик матур булды. 6. Айсылу дусларча киңәш бирде. 7. Илгиз быел шактый күп китап укыды.

**5.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп языгыз.

1. Мин мәсьәлә... тиз чиштем, ә Рамил мисал... бик озак эшләде. 2. Дәфтәрләр... сыйныф җитәкчесе еш тикшерә. 3. Мин бу китап... иртәгә укыйм. Ә син аны кичә укыдыңмы?

**6.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез. Рәвешләрне билгеләгез.

1. — Син бүген бик тиз килдең.
— Мин автобус белән килдем.
— Кичә ник соңга калдың?
— Озак йоклаганмын.

2. — Син ни өчен өй эшен бик озак эшләдең?
— Мисалны тиз эшләдем, мәсьәләне озак чиштем.
— Абыең булышмадымы?
— Булышмады. Абыем дусларына китте, алар бик ерак торалар.

3. — Дәрес әзерләргә кем булыша?
— Әти дә, әни дә эштә. Үзем эшлим.
— Мин дә үзем эшләргә тырышам.

**7.** Диалогларга нокталар урынына җаваплар языгыз. Дустыгыз белән сөйләшегез.



— Син бүген китапханәгә барасыңмы?
— ... . Ә син?
— Мин кичә бардым, бүген барырга вакыт юк.
— Быел ничә китап укыдың?
— ... .
— Нәрсә турында укыдың?
— ... .
— Сезнең өегездә нинди китаплар бар?
— ... .

**8.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Сания апа, миңа китап бирегез әле.
— Син нәрсә турында укырга яратасың?
— Мин сәяхәтләр, кызыклы хәлләр турында укырга яратам.
— Менә алайса Жюль Вернның «Унбиш яшьлек капитан»ын яки «Капитан Грант балалары»н ал. Александр Дюманың «Граф Монте Кристо» романы да бик кызык.
— Рәхмәт, Сания апа. Мин Жюль Верннан башлыйм, яшь капитан турында алам.

2. — Илгиз, син бүген китапханәгә барасыңмы?
— Юк, әле китабымны укып бетермәдем. Ә син?
— Мин кичә бардым, бүген вакытым юк.
— Быел ничә китап укыдың?
— Санамадым, бик күп укыдым.
— Нәрсә турында укыдың?
— Маҗаралы хикәяләр укырга яратам.
— Синең өеңдә китаплар бармы?
— Әйе, зур китапханәбез бар. Андагы бөтен китапларны укып чыктым инде.

**9.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: Илгизнең өендә нинди авторларның китаплары бар?




## 16 нчы дәрес

**1. Исегезгә төшерегез!**

В татарском языке аффиксы присоединяются к основе существительных в следующем порядке: аффиксы множественного числа и аффиксы принадлежности, падежные аффиксы.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Основа | + | аффикс множ.числа | + | аффикс принадлеж. | + | аффикс падежа |
| Күз | + | ләр | + | ем | + | нең |

**2.** Төрләнешне дәвам итегез, җөмләләр уйлагыз.

минем дәфтәрем
синең ...
аның ...

безнең ...
сезнең ...
аларның ...

**3. Китапларыбызны** сүзендә нинди аффикслар бар? **Белге, имтихан** сүзләренә шул ук аффиксларны ялгап, җөмләләр төзегез.

**4.** Диалогны укыгыз һәм үзара сөйләшегез.

— Саша, минем китабыма тимә.
— Юк, Луиза, бу китап синеке түгел. Ул минем китабым.
— Ә минеке кайда?
— Синең китабың өстәлдә.
— Юк, ул китап Веранықы.
— Урындыкта кемнең китабы?
— Ул да минеке түгел, Оляныкы.
— Синең китабың шкафтадыр. Кара әле.
— Әйе, минем китабым шкафта.

**5.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: китаплар кемнеке? 4 нче күнегү эчтәлеген файдаланыгыз.



**6.** Спросите у друга:

— чья эта книга;
— сколько стоит эта книга;
— нужна ли ему эта книга;
— нет ли у них дома книги о Казани;
— есть ли у него татарско-русский словарь;
— где находится городская библиотека.

**7.** Посоветуйте другу:

— беречь книги;
— слушать преподавателя;
— не опаздывать на урок;
— писать аккуратно;
— хорошо отвечать на уроках.

# 17–18 нче дәресләр

**1.** Танылган шәхес Разил Вәлиев турында укыгыз.



Разил Исмәгыйль улы Вәлиев Татарстанның Түбән Кама районы Ташлык авылында 1947 нче елда туа. Беренче шигырьләрен мәктәп елларында яза, алар район газетасында басылып чыга. Урта мәктәпне бетергәч, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә, укуын Мәскәүдә Әдәбият институтында дәвам итә. 1971 нче елда Казанда беренче китабы басылып чыга.

1986–2000 нче елларда Татарстан Республикасының Милли китапханәсе директоры булып эшли. Аңа Муса Җәлил премиясе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Балалар өчен язылган әсәрләре Абдулла Алиш премиясенә лаек була.

Разил Вәлиев — шагыйрь генә түгел, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе дә була. Озак еллар буе Татарстан Югары Советында депутат вазифасын башкара.

Разил Вәлиевнең тәрҗемә эшләре дә күп. Р. Киплингның «Маугли», А. Экзюперинең «Нәни принц» повестьларын, дөнья халыклары әкиятләрен аның тәрҗемәсендә балалар яратып укыйлар. Р. Вәлиев Казанда яши һәм эшли. Ул 2023 нче елның 20 нче октябрендә вафат була.

**лаек була** — здесь: был удостоен
**җәмәгать эшлеклесе** — общественный деятель

**2.** Тексттан тартымлы исемнәрне табып, аларның зат-санын, килешен билгеләгез.

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Разил Вәлиев беренче шигырьләрен ... . 2. Алар район газетасында ... . 3. Урта мәктәпне бетергәч, ... .

4. 1971 нче елда аның Казанда беренче китабы ... . 5. Ул 1986–2000 нче елларда Татарстан Республикасының Милли китапханәсе директоры ... . 6. Разил Вәлиевкә Муса Җәлил премиясе ... . 7. Балалар өчен язылган әсәрләре ... .

**4.** Тексттан җөмләләрнең тәрҗемәсен табыгыз.

1. Разил Валиев был не только поэтом, но и публицистом и общественным деятелем.
2. Он лауреат премии имени Габдуллы Тукая.
3. Разил Валиев жил и работал в Казани.

## 19–20 нче дәресләр

**1.** Сүзтезмәләрне һәм сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемәсен әйтегез.

Иртә таңнан бирле, ачулы, һаман, елый, язып, гаепле берүзем, моңа кадәр, чират, карт, кызгану, кызганыч, кызганмый, тырыша.

**2.** Үрнәк буенча тәрҗемә итегез.

1) эштә — на работе
эштә иде — был на работе
урамда — ...
урамда иде — ...
өйдә — ...
өйдә иде — ...
2) үзем алдым — сам взял
әнидән сорап алдым — взял, попросив у мамы
үзем чиштем — ...
әтидән сорап чиштем — ...
үзем киттем — ...
ападан сорап киттем — ...
үзем бирдем — ...
әбидән сорап бирдем — ...

3) елый — плачет
   елый иде — плакал(а)
   чишә — ...
   чишә иде — ...
   булыша — ...
   булыша иде — ...

**3.** Алмашлыкның килеш белән төрләнешен исегезгә төшерегез. Җөмләләр төзегез.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Б.к. | үзем | Т.к. | үземне |
| И.к. | үземнең | Ч.к. | үземнән |
| Ю.к. | үземә | У.-в.к. | үземдә |

**4.** Шигырь белән танышыгыз. Икеле билгесе алганга кем гаепле?

**Икеле**

Бүген иртә таңнан бирле
Әти ачулы һаман:
— Кичә икеле алгансың,
Нәрсә булды, Рамазан?!

Елый язып әйттем аңа:
— Гаепле,— дип,— икегез,
Мин берүзем нишли алам?
Сез бит эштә идегез.

Моңа кадәр мәсьәләне
Чиштем әнидән сорап.
Дәрес әзерләргә, әти,
Бүген бит синең чират.

Әбиебез карт шул инде...
Кызганмыйсыз да аны.
Кичә, күпме тырышса да,
Әби икеле алды.

Р. Вәлиев

**таңнан бирле** — с утра



Разил Вәлиев шигырьләрен укы

**5.** Шигырьдән зат алмашлыкларын табыгыз, сораулар куегыз, килешен билгеләгез.

**6.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

1. Рамазан икеле алганга үзе гаепле.
2. Рамазанның әти-әнисе гаепле.
3. Рамазан дәресләрне әнисеннән сорап әзерләгән.
4. Әбисе Рамазанга булыша алмаган.

**7.** Диалогларны укыгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

1. — Син кайчан тордың?
— И, әллә кайчан, иртә таңнан.
— Нәрсә булды?
— Имтиханга әзерләндем.

2. — Тәлинкәне кем ватты?
— Мин гаепле, ялгыш ваттым.
— Ярый, борчылма, ялгыш була инде ул.

**8.** Спроси у друга:

— сделал ли он домашнее задание;
— какие оценки он получил сегодня;
— какие уроки ему нравятся;
— правильно ли он решил задачу;
— сколько уроков было сегодня;
— была ли контрольная работа по математике.

**9.** Скажи о том, что ты:

— хорошо работал на уроке и по математике получил «5»;
— написал диктант без ошибок;
— сделал контрольную работу на отлично;
— очень быстро решил пример и задачу;
— долго выполнял домашнее задание.

## 21–24 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укыгыз. Автор ни өчен шигырьнең исемен «Киңәш» дип атаган?

### Киңәш

Күзең белән кара син,
Күңелең белән уйла син,
Уең уйлап, язуыңны
Ялгыш язып куйма син.
Кат-кат уйла хисапны,
Дөрес чыгар шул чакны.

Уйла җитез, уйла тиз,
Биш кат үлчә, бер кат кис!
Дәфтәрең чиста булсын,
Китабың көлеп торсын,
Ачып җибәргәндә син,
Үзлегеннән укылсын!



Ш. Маннур

**хисап** — математический счёт
**дөрес чыгар** — будет правильно
**үзлегеннән укылсын** — пусть непроизвольно читается
**җитез** — шустро

**2.** Шигырьдән II зат боерык фигыльләрне табыгыз. Бу фигыльләр ярдәмендә автор укучыларга нинди киңәшләр бирә?

**3.** Шигырьдәге киңәшләрне бер-берегезгә әйтегез.

**4.** Шигырьдән мәкальне табыгыз. Сез аны ничек аңлыйсыз?

**5.** Яхшы уку өчен кирәкле кагыйдәләрне искә төшерегез. Сез тагын нинди кагыйдәләр өстәр идегез?

— Яхшы уку өчен, дәрестә игътибарлы булырга кирәк.

— Яхшы уку өчен, көн дә дәрес әзерләргә кирәк.
— Яхшы уку өчен, яңалыкларны белергә кирәк.
— Яхшы уку өчен, дәфтәр, китапларны өйдә онытмаска кирәк.
— Яхшы уку өчен, ... .

**6.** Посоветуйте другу:

— внимательно слушать учителя;
— чётко отвечать на уроке;
— быстрее думать;
— не писать с ошибками;
— семь раз отмерить, один раз отрезать;
— внимательно читать задание в учебнике.

**7.** Диалоглардан фигыльләрне табыгыз. Диалогларны үзара сөйләшергә өйрәнегез.

1. — Петя, син бу җөмләне дөрес язмагансың.
— Нигә алай дисең?
— Хатаң бар бит. Игътибар белән кабат укы.
— Әйе шул, хатам бар.

2. — Син кичә нишләдең?
— Дәрес әзерләдем. Мәсьәләләр чиштем, сочинение яздым. Ә син нишләдең?
— Мин дә дәрес әзерләдем. Инглиз телен кабатладым. Татар теленнән күнегүләр эшләдем.
— Тагын нишләдең?
— Әнигә булыштым. Идән юдым, кибеткә бардым.

3. — Айнур, мәсьәләне чиштеңме?
— Юк, уйлыйм, уйлыйм, чишеп булмый.
— Схема төзеп кара.
— Әйе шул, хәзер эшләп карыйм.

4. — Гөлшат Илдусовна, мин ялгыш яздым. Кабат язсам ярыймы?
— Әлбәттә, ярый. Дәфтәреңә дөрес итеп кабат яз.

**8.** Яхшы уку өчен нәрсәләр кирәк? Таблицаны тутырыгыз.

| Яхшы укучыга хас сыйфатлар | Яхшы уку кагыйдәләре |
| --- | --- |
| ... | ... |

**9.** Как скажете о том, что:

— вы говорите на татарском языке;
— вы сами решили задачу;
— вы пишете внимательно, без ошибок?

**10.** Түбәндәге схема буенча диалоглар төзегез.

— совет
— вопрос
— убеждение
— согласие

Т е м а л а р: 1. Укучының дәрестәге тәртибе. 2. Укучының китапка карашы. 3. Яхшы укырга өндәү.

**11.** Как спросите у подруги:

— какие предметы есть в расписании;
— сколько уроков будет завтра;
— как зовут нового классного руководителя;
— каким уроком будет английский язык;
— будет ли у вас сегодня урок литературы;
— приготовила ли она домашнее задание;
— что им задали на дом;
— какие оценки она получила сегодня;
— какие уроки ей нравятся;
— правильно ли она решила задачу;
— правильно ли она решила примеры;
— много ли задали домашнего задания?

**12.** Бу фикерләр белән килешәсезме? Төркемнәрдә фикерләшегез. Фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән раслагыз, дәфтәрләргә языгыз.

— Эшмәкәр булу өчен белем кирәкми.
— Эшмәкәр булу өчен кыюлык та җитә.
— Надан (неграмотный) кеше дә яхшы эшли ала.
— Надан булуга караганда, белемле булу яхшырак.

**13.** Түбәндәге схемалар буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

1) — совет
— вопрос
— убеждение
— согласие

2) — вопрос
— отрицание
— убеждение
— согласие

**14.** Бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Фикерләрегезне дәфтәрләргә языгыз. Сөйләргә өйрәнегез.

Белем байлыктан кыйбат.
Надан белмәсә дә, кычкыра.
Бер галим 100 наданны җиңә.

**15.** Поговорите с другом.

— Сез татар теле дәресендә нишлисез?
— Без татар теле дәресендә укыйбыз, күнегү эшлибез, диктант язабыз.
— Сез математика дәресендә нишлисез?
— Без математика дәресендә мәсьәләләр чишәбез, мисаллар эшлибез.
— Сиңа геометрия ошыймы?
— Әйе. Мин теоремалар исбатларга яратам.

# МИН ҺӘМ МИНЕМ ЯШЬТӘШЛӘРЕМ



## 25–27 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Тырыш** — старательный, **чибәр, матур** — красивый, **тупас** — грубый, **тәрбияле** — воспитанный, **тәрбиясез** — невоспитанный, **игътибарсыз** — невнимательный, **эшчән** — трудолюбивый, **горур** — гордый, **әдәпле** — вежливый, **ялкау** — ленивый, **алдакчы** — врун, **тыйнак** — скромный, **тәмле телле** — красноречивый, **җитди** — серьёзный, **куркак** — трусливый, **акылсыз** — глупый, **акыллы** — умный, **надан** — неграмотный.

2. Бирелгән сүзләрдән сыйфатлар ясагыз.

| | **-лы/-ле** | **-сыз/-сез** |
|---|---|---|
| тәрбия | тәрбияле | тәрбиясез |
| әдәп | | |
| чәч | | |
| игътибар | | |
| күңел | | |
| кирәк | | |

**3.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| ябык | | яңача |
| тупас | | акрын (әкрен) |
| искечә | **?** | таза |
| искелек | | әдәпле |
| тиз | | яңалык |

**4.** Сыйфатларны таблицага языгыз. Алар белән җөмләләр төзегез.





| Тышкы кыяфәтен белдерү | Характер сыйфатларын белдерү |
|---|---|
| ... | ... |

Сыйфатлар: ябык, таза, юан, тупас, озын, кыска, аралашучан, оялчан, олы, әдәпле, кечкенә, тәрбиясез, матур, киң күңелле, киң җилкәле, гадел, озын чәчле, кыска чәчле, кара чәчле, сары чәчле.

**5.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Оля, минем белән кибеткә бар әле.
   — Нәрсә аласың?

— Мин үземә күлмәк эзлим.

— Муса Җәлил урамындагы кибеттә матур күлмәкләр бик күп.

— Минем буем бик озын шул.

— Анда озын буйлы кызларга да, кечкенә буйлы кызларга да, ябык һәм таза кызларга да күлмәкләр күп.

— Ярар, шунда барыйк.

2. — Мансур, син үзең бик шаян егет. Ә дустың Айдар бер дә сөйләшми, тыныч. Сез ничек дус була аласыз?

— Айдар — бик гадел, игътибарлы, әдәпле, киң күңелле егет. Ул мине тыңлый белә. Аның белән дус булу бик рәхәт. Ул — чын дус.

**6.** Үрнәктәгечә тәрҗемә итегез.

Үрнәк: Они думают, что быть воспитанным — это не модно. — Алар әдәпле булу модада түгел, дип уйлыйлар.

1. Они думают, что быть красивым — самое большое счастье.
2. Они думают, что быть богатым — самая большая мечта.
3. Они думают, что быть воспитанным совсем необязательно.

**7.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Настя, сиңа Дамир ошыймы?

— Юк, бигрәк ябык бит ул, ошамый.

— Юк, Настя, дөрес уйламыйсың. Ә нинди акыллы, тәрбияле ул Дамир.

— Әйе шул, кызларга да тупас эндәшми, булыша.

2. — Айгөл, син беләсеңме, безнең сыйныфка яңа егет килде?

— Кайдан күчкән?

— Башка шәһәрдән.
— Нинди соң ул?
— Ул бик матур, озын буйлы, кара чәчле.
— Характеры нинди?
— Белмибез әле.

**8.** 7 нче күнегүдәге диалогларга охшаш диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**9. Исегезгә төшерегез!**

**укы-са́** — если прочитает
**укы́-ма-са** — если не прочитает
**әйт-сә́** — если скажет
**ә́йт-мә-сә** — если не скажет

**10.** Ничек уйлыйсыз, нинди кешеләр белән дуслашып була яки дуслашып булмый? Фикерләрегезне төркемнәрдә уртаклашыгыз.

Әгәр кеше
- тупас
- әдәпле
- оялчан
- киң күңелле
- усал

булса
- ... .
- ... .
- ... .
- ... .
- ... .

**11.** Как скажете о том, что:

— у вас есть друг;
— ваш друг высокого роста, худощавый, темноволосый (брюнет);
— вы с ним вместе играете, готовите уроки, ходите в школу;
— он умный, воспитанный?

# 28–30 нчы дәресләр

1. **Исегездә тотыгыз!**

В татарском языке многие слова заимствованы из арабского и персидского языков. Например: **гаеп** — вина, **канәгать** — довольный, **гади** — обычный, **кагыйдә** — правило, **табигать** — природа, **әдәбият** — литература, **мәктәп** — школа.

Правописание таких слов нужно запомнить.

2. Сүзләрнең тәрҗемәсен искә төшерегез.

1) танышу кагыйдәләре — ...
әдәп кагыйдәләре — ...
юл йөрү кагыйдәләре — ...
исәнләшү кагыйдәләре — ...

2) кайберәүләр — ...
кайчак — ...
кайдадыр — ...

3) һәрвакыт — ...
һәркайда — ...
һәркайчан — ...

3. Бу сүзләрне исегезгә төшерегез. Аларны кайчан кулланалар?

Сәламәт бул(ыгыз)! Хәерле юл! Зинһар өчен! Гафу ит(егез)! Ашыгыз тәмле булсын! Хәлләр(егез) ничек? Тыныч йокы! Рәхим ит(егез)!

4. Бу сүзләрне кулланып, җөмләләр төзегез.

Хәерле көн! Мөмкин булса, ... . Әйтегезче, ... .

5. Нокталар урынына төшеп калган хәрефләрне өстәп языгыз. Сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз.

Г...ди, кагыйд...ләр, кайб...р, м...гънә, б...рк...м, өлк...н, игът...бар, к...н...г...ть, г...еп, ис...нл...шү.

**6.** Бирелгән сүзләрнең капма-каршы мәгънәләрен әйтегез.

| | |
|---|---|
| зарланалар | өлкән сыйныфлар |
| үз-үзен тота белә | чакырдылар |
| игътибар итә | аңлый ала |
| канәгать | кирәксез |

**7.** Эльвираның «Ялкын» журналына язган хатын укыгыз.

Әдәп кагыйдәләрен дә кайберәүләр кирәксез дип саный. Ә соңыннан үзләре: «Мине яратмыйлар», — дип зарланалар. Минем бер таныш кызым бар. Башлангыч сыйныфларда укыганда, ул тупас, үз-үзен тота белми иде. Ләкин беркем дә моңа артык игътибар итмәде. Ә өлкән сыйныфларда иптәшләре аннан читләшә башлады. Аны бәйрәмгә дә, туган көнгә дә чакырмадылар. Ләкин ул моның сәбәбен һаман аңлый алмый. Чөнки ул үз-үзеннән бик канәгать һәм һәрвакыт гаепне башкалардан эзләргә ярата.

**читләшә башлады** — здесь: начали сторониться
**сәбәп** — причина

**8.** Бу җөмләләр текст эчтәлегенә туры киләме?

1. Әдәп кагыйдәләрен барлык кешеләр дә үти. 2. Минем таныш кызым әдәп кагыйдәләрен үтәми. 3. Ул башлангыч сыйныфларда әдәп кагыйдәләрен үти иде, өлкән сыйныфларда үтәми башлады. 4. Иптәш кызым үз-үзеннән канәгать түгел, гаепне башкалардан эзләргә яратмый.

**9.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Дуслары Эльвираның таныш кызыннан нигә читләшәләр? 2. Бу кызның төп гаебе нәрсәдә?

**10.** Приветствуя товарища, поинтересуйтесь, как у него дела.

**11.** Представьте свою подругу друзьям.

Ашау әдәпләрен бел

**12.** Как скажете о том, что ваш друг:

— вежливый;
— воспитанный;
— внимательный;
— весёлый
— добрый?

**13.** Предложите другу после уроков играть в футбол.

**14.** Предложите Насте:

— подружиться;
— встретиться;
— записаться в кружок;
— вместе ходить в школу.

## 31–32 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен өйрәнегез.

**әләкче** — доносчик, ябеда
**әләкләшергә** — доносить, ябедничать
**ватык** — разбитый
**ватты** — разбил

**2.** Үрнәк буенча тәрҗемә итегез.

а) эшләргә ярата — любит работать
әләкләшергә ярата — ...
алдашырга ярата — ...

ә) эшли башлады — начал работать
әләкләшә башлады — ...
алдаша башлады — ...

**3.** Хикәяне укыгыз. Мидхәт нигә кып-кызыл булды?

## Әләкче

Безнең класста бер Мидхәт исемле малай бар. Ул бик әләкче, гел әләкләшергә ярата. Нәрсә дә булса ишетсә, тиз генә я укытучы, я тәрбияче янына йөгерә.

Беркөнне без бу әләкче малайны акылга өйрәтергә уйладык.

Зур тәнәфестә мин Мидхәт янына килдем дә:

— Тәрәзәне ваттылар, — дидем.

Мидхәт, күзләрен зур ачып:

— Кемнәр? — дип сорады.

— Фатих бугай.

Мидхәт озак уйламады, укытучылар бүлмәсенә йөгерде. Тиздән безнең укытучы класска керде. Ул тәрәзәләрне карады. Тәрәзә ватык түгел иде. Башка классларга да керде. Анда да тәрәзә ватык түгел иде. Укытучы Мидхәтне эзли башлады. Мидхәт чишенү бүлмәсендә иде.

— Тәрәзәне кем ватты дидең, Мидхәт? — дип сорады укытучы.

— Фатих инде, Фатих!

Без барыбыз да көлә башладык.

— Авырый ич Фатих! Бүген укырга да килмәде, — дидек.

— Кайсы тәрәзә ватылды? Күрсәт әле, — диде укытучы.

— Белмим... мин... миңа... күрмәдем...

— Күрмәсәң, нигә сөйлисең?

Мидхәт кып-кызыл булды, бер сүз дә әйтә алмады.

З. Әхмәровтан

**бугай** — кажется
**эзли башлады** — начал искать
**ишетсә** — если услышит
**акылга өйрәтергә уйладык** — решили проучить
**чишенү бүлмәсе** — раздевалка

**4.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[wa°тты́], [йөгердө́], [кү́рмәдә̆м], [a°кы́л], [кы́п-кы̆зы́л].

**5.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Мидхәт әләкче малай түгел.
   Мидхәт — әләкче малай.

2. Мидхәт әләкләшергә яратмый.
   Мидхәт әләкләшергә ярата.

3. Фатих укырга килгән иде.
   Фатих укырга килмәгән иде.

4. Фатих тәрәзәне ватты.
   Фатих тәрәзәне ватмады.

5. Укытучы Мидхәтне эзләде.
   Укытучы Мидхәтне эзләмәде.

6. Мидхәт кып-кызыл булды.
   Мидхәт кып-кызыл булмады.



**6.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп языгыз. Текстны сөйләргә өйрәнегез.

1. Мидхәт бик әләк... , ул гел әләкләшергә ярат... . 2. Укучылар Мидхәт... акылга утыртырга уйлады... . 3. Зур тәнәфес... бер укучы Мидхәт яны... килде дә: «Тәрәзә... ваттылар»,— диде. 4. Мидхәт әләкләшергә укытучы яны... йөгер... . 5. Фатих мәктәпкә килмә... иде. 6. Укытучы Мидхәт... чишенү бүлмәсеннән тап... . 7. Мидхәт бер сүз дә әйтә алма... .

**7.** Бу җөмләләрне кем әйтте, исегезгә төшерегез.

— Тәрәзәне ваттылар,— диде ... .
— Кемнәр? — дип сорады ... .
— Фатих бугай,— диде ... .
— Тәрәзәне кем ватты дидең, Мидхәт? —дип сорады ... .
— Фатих инде, Фатих,— диде ... .
— Авырый ич, Фатих! Бүген килмәде,— диделәр ... .
— Кайсы тәрәзә ватылды, күрсәт әле,— диде ... .

— Белмим, мин күрмәдем,— диде ... .
— Күрмәсәң, нигә сөйлисең,— диде ... .

8. Хикәяне рольләргә бүлеп укыгыз, сәхнәләштерегез.

9. Сорауларга җавап бирегез.

1. Мидхәт нинди малай? 2. Классташлары нишләргә уйладылар? 3. Алар нинди план кордылар? 4. Ни өчен Мидхәт бер сүз дә әйтә алмады?

10. Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Укучылар Мидхәт белән дус түгел, чөнки ... . 2. Мидхәт әләкләшә, шуңа күрә ... . 3. Мидхәт кып-кызыл булды, чөнки ... . 4. Мидхәт алдашты, шуңа күрә ... . 5. Мидхәтне акылга утыртырга уйладылар, чөнки ... . 6. Мидхәт әләкләшә, шуңа күрә аны ... .

11. Как скажете о том, что:

— сегодня Аня не пришла в школу, она болеет;
— на перемене нечаянно разбили окно;
— в вашем классе нет ябед;
— в нашем классе нет разбитых окон?

12. Ничек уйлыйсыз, классташлары Мидхәт белән дус булырга телиләрме? Сез Мидхәткә нинди киңәшләр бирер идегез?

## 33–34 нче дәресләр

1. Хикәяне укыгыз. Уйлап карагыз, хикәя геройлары чын дусләрмы?

### Сашаның дуслары

Сашаның дуслары күп. Ләкин аның ин якын дуслары икәү генә. Алар — Валера белән Азат. Дуслар гел бергә йөри: мәктәпкә дә, спорт түгәрәгенә дә, китапханәгә дә.

Алар бергә уйныйлар, бергә дәрес әзерлиләр. Туган көннәрен, бәйрәмнәрне бергә үткәрәләр.

Бервакыт Сашаның әбисе авырды. Аның йөрәге авыртты, кан басымы күтәрелде.

— Улым, даруханәдән йөрәк даруы алып кайт әле, — диде әбисе Сашага.

Саша акча алды һәм даруханәгә йөгерде. Ләкин даруханәдә акчасын тапмады. Хәзер нишләргә? Саша кире өйгә кайтырга уйлады. Юлда дусларын күрде һәм ярдәм сорады. Валераның акчасы бар, ләкин ул аны Сашага бирмәде. «Үземә кирәк», — диде. Ә Азат: «Мин хәзер»,— диде дә өенә йөгерде. Ул якын тора иде. Азат яңа уен алырга акча җыйган иде. Шул акчаны дустына бирде.

Икенче көнне Валера Сашаны уйнарга чакырды, ләкин Сашаның чыгасы килмәде.

**2.** Хикәядән бирелгән эчтәлектәге җөмләләрне табып укыгыз.

1. Сашаның иң якын дуслары.
2. Сашаның әбисе авырый.
3. Саша акчасын югалтты.
4. Валера Сашага ярдәм итми.
5. Азат Сашага ярдәм итә.

**3.** Хикәянең эчтәлегенә туры килгән җөмләләрне сайлап алып, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Сашаның әбисе авырды.
2. Валера Сашага акча бирде.
3. Әбинең йөрәге авыртты, кан басымы күтәрелде.
4. Валера Азатны уйнарга чакырды.
5. Сашаның иң якын дуслары икәү генә.
6. Саша дусларыннан ярдәм сорады.
7. Сашаның колагы, башы, тамагы авыртты.
8. Саша даруханәдән йөрәк даруы алып кайтты.

**4.** Ике раслауның кайсысы дөрес? Дөрес вариантны дәфтәрегезгә языгыз.

1. Валера Сашага акча бирде. Азат Сашага акча бирде.
2. Сашаның дусты авырды, Сашаның әбисе авырды.

3. Азатның йөрәге авыртты, кан басымы күтәрелде. Әбинең кан басымы күтәрелде, йөрәге авыртты.

4. Сашаның якын дуслары күп. Сашаның якын дуслары икәү генә.

5. Валера, Азат уйнарга чыктылар. Азат уйнарга чыкмады.

6. Азат — яхшы, игътибарлы дус, Валера — яхшы, игътибарлы дус.

**5.** Диалогларны «Сашаның дуслары» хикәясе эчтәлеге тәртибе буенча урнаштырыгыз. Үзара сөйләшегез.

1. — Валера, миңа акча биреп тор әле.
— Юк, Саша, үземә кирәк.

2. — Саша, синең якын дусларың күпме?
— Юк, минем якын дусларым икәү генә.

3. — Азат, әйдә уйнарга чыгабыз.
— Юк, Валера, минем уйнарга чыгасым килми.

4. — Әбием, синең кай җирең авырта?
— Минем йөрәгем авырта, кан басымым югары.

5. — Улым, даруханәдән йөрәк даруы алып кайт әле.
— Ярар, әбием.

6. — Дусларым, ярдәм итегез, минем әбием авырый, дару кирәк, ә мин акчамны югалттым.
— Мә, Саша, әбиеңә дару ал.

**6.** Җөмләләргә сораулар куегыз.

1. Сашаның дуслары күп. 2. Алар бергә уйныйлар, дәрес әзерлиләр. 3. Әбинең йөрәге авыртты, кан басымы күтәрелде. 4. Саша юлда дусларын күрде һәм ярдәм сорады. 5. Азат дустына ярдәм итте. 6. Валера Азатны уйнарга чакырды.

**7.** Сез ничек уйлыйсыз, Саша, Азат һәм Валера чын дуслармы? Фикерләрегезне дәлилләгез, раслауларны төгәлләгез.

— Азат — чын дус, чөнки ... .
— Валера чын дус түгел, чөнки ... .

**8.** Әгәр хикәядә өч малай да чын дуслар булса, хикәя ничек үзгәрер иде? Хикәяне язып карагыз.

**9.** Дәреслектәге һәм үзегез язган хикәяне сәхнәләштерегез.

**10.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Кайсы хикәядә малайлар чын дуслар?
2. Чын дуслар нинди була?
3. Кайсы хикәядә малайларга бергә күңеллерәк, рәхәтрәк?

**11.** Үзегез язган хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

## 35–37 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Имя действия (исем фигыль)** — это форма глагола, которая имеет признаки глагола и имени существительного. Образуется присоединением к основе аффиксов **-у/-ү**: кайту, китү, әзерләү, керү.

| Барлык формасы: | Юклык формасы: |
| --- | --- |
| **Нишләү?** | **Нишләмәү?** |
| ярат + **у** (ярату) | ярат + ма + **у** (яратмау) |
| җый + **у** (җыю) | җый + ма + **у** (җыймау) |
| ти + **ү** (тию) | ти + мә + **ү** (тимәү) |
| тап + **у** (табу) | тап + ма + **у** (тапмау) |

Ярдәмгә — плакатлар!

**2.** Бирелгән фигыльләрдән исем фигыльнең барлык һәм юклык формаларын ясагыз.

Үрнәк: кайгыртырга — кайгырту — кайгыртмау.

Анализларга, бәяләргә, аралашырга, бетерергә, сорау бирергә, эшләргә, сөйләшергә, игътибар итәргә.

**3.** Бирелгән сүзләрдән сүзтезмәләр ясагыз һәм алар белән җөмләләр төзеп языгыз.

иркен, кызык итеп, сөйләшүне, аралашучан — ? — булу, тоту, туктату, сөйләү

**4.** Нокталар урынына терәк сүзләрне куеп укыгыз.

1. Әңгәмәдәшеңә сораулар ... дә бик мөһим.
2. Матур, дөрес сөйләргә ... өчен, күп укырга кирәк.
3. Үзеңнең кимчелекләреңне ... өчен, уйларга һәм тырышырга кирәк.
4. Үз ялгышларыңны ... бик авыр.

Терәк сүзләр: төзәтү, бирү, тану (признание), өйрәнү.

**5.** Бирелгән сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, сүзлектән тәрҗемәләрен табыгыз.

Ялгыш, мөнәсәбәт, адым, иркен, уртак, аралашучан, ялгыз, үз-үзеңне тоту, авырлык, әңгәмәдәш.

**6.** Фигыльләрнең тәрҗемәләрен табыгыз, аларны юклык формасында языгыз.

белергә, бәяләргә, анализларга, өйрәнергә, калырга, эшләргә — ? — анализировать, оценивать, научиться, остаться, работать, уметь

**7.** Сез яшьтәшләрегез белән ничек аралашасыз? Сез аралашучанмы (общительный)? Психолог киңәшләрен укыгыз. Кешеләр белән аралашу (общение) авыр булса, нишләргә?

Һәр кеше үзенең тәртибен анализларга, хаталарын, ялгышларын танырга, кешеләр белән аралашудагы кимчелекләрен

бетерү өстендә эшләргә тиеш. Үзеңнең әңгәмәдәшең белән бер дәрәҗәдә торып сөйләшү әһәмиятле.

Үзеңне иркен тотып, кызык итеп сөйли белү, сораулар бирү, сөйләшүне үпкәләшмичә генә туктата белү дә мөһим. Димәк, тәмле телле, аралашучан кеше булу өчен, күп нәрсәләргә өйрәнергә кирәк икән.



Кешеләр арасында җылы мөнәсәбәт, игътибар җитмәү, уртак тел таба алмау күп кенә авырлыклар, күңелсезлекләр китереп чыгара. Әгәр син ялгыз калырга теләмәсәң, яхшы дусларың булсын дисәң, тәртибең, үз-үзеңне тотышың турында һәрвакыт кайгырт.

Вакытлы матбугаттан

**дәрәҗә** — здесь: уровень
**үпкәләшмичә** — не обижая друг друга
**мөһим** — важно

**8.** План пунктларына туры килгән абзацларны тексттан табып укыгыз.

1. Матур аралашуның шартлары.
2. Сөйләү осталыгы.
3. Кешеләр белән аралашканда күңелсезлекләр килеп чыгу сәбәпләре.

**9.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Төркемнәрдә үзара сөйләшегез.

— Әгәр син ялгыз калырга теләмәсәң, яхшы дусларың булсын дисәң, тәртибең, үз-үзеңне тотышың турында һәрвакыт кайгырт.

— Әхлак (мораль) һәрвакыт хөрмәттән башлана: кешеләргә, үз-үзеңә, табигатькә хөрмәт...



# БУШ ВАКЫТ



## 38–40 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен өйрәнегез.

**буш вакытта** — в свободное время
**ошый** — нравится
**яраткан шөгыль** — любимое занятие (увлечение)
**файдалы** — полезный
**дәрестән соң** — после уроков
**спорт түгәрәге** — спортивный кружок
**ял итәм** — отдыхаю
**берәүләр** — одни
**кайберәүләр** — некоторые
**кемнәрдер** — кто-то

**2.** Ләйсән исемле кыз «Ялкын» журналына менә нинди фикерләр язып җибәргән. Сез аның сорауларына ничек җавап бирер идегез?

Буш вакыт... Ул нинди вакыт? Аны ничек файдаланырга? Бу сорауларга төрлечә җавап бирәләр. Берәүләр: «Буш вакыт ул минем өчен. Мин үзем теләгәнчә яшим. Я урамда йөрим, я тик ятам», — ди. Икенчеләр: «Мин, буш вакытым булса, бертуктаусыз төрле фильмнар карар идем», — ди. Өченчеләр: «Буш вакыт ул — дәрестән тыш вакыт, өйдә булышканнан соң калган вакыт. Ул — ирекле вакыт, теләсәң ни эшләргә була», — диләр. Кайберәүләр буш вакытта төрле китаплар укырга яраталар. Ә кемнәрдер театр, концертларга йөриләр. Шунысы ачык: буш вакытны файдалы яки файдасыз үткәрергә

була. Миңа калса, буш вакытны файдалы үткәрсәң, үзеңә яхшы була. Шуңа күрә дә мин, буш вакытым булса, я китап укыйм, я әтием белән шахмат уйныйм. Әлбәттә, телевизордан кызыклы тапшырулар булса, аларны да онытмыйм. Ләкин урам буйлап бер файдасызга тик йөрүне һич яратмыйм. Әле кайбер кызлар һәм малайларның кулында сигарет, пиво шешәләре дә күрәсең. Шунысы аңлашылмый: моннан кемгә файда?

**үзем теләгәнчә** — по-своему
**тик йөрү** — бездельничать
**моннан** — от этого, отсюда

**3.** Тексттан буш вакыт турындагы фикерләрне табып укыгыз, бер-берегезгә сөйләгез.

**4.** Бу фикерләр белән килешәсезме? Ни өчен алай уйлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

— Буш вакыт — ул минем өчен. Мин үзем теләгәнчә яшим. Я урамда йөрим, я тик ятам.

— Мин, буш вакытым булса, бертуктаусыз төрле фильмнар карар идем.

— Буш вакыт ул — дәрестән тыш вакыт, өйдә булышканнан соң калган вакыт. Ул — ирекле вакыт, теләсәң ни эшләргә була.

— Буш вакытым булса, я китап укыйм, я әтием белән шахмат уйныйм. Әлбәттә, телевизордан кызыклы тапшырулар булса, аларны да онытмыйм.

**5. Исегездә калдырыгыз!**

**Җөмлә кисәкләре**
**Члены предложения**

Җөмлә (предложение) тәмамланган уй-фикерне белдерә. **Ия** (подлежащее) белән **хәбәр** (сказуемое) җөмләнең **баш кисәкләре** (главные члены) дип атала. Ия белән хәбәрдән башка кисәкләр **иярчен кисәкләр** (второстепенные члены) дип йөртелә. Иярчен кисәкләргә **аергыч** (определение), **хәл** (обстоятельство), **тәмамлык** (дополнение) керә.

**6.** 2 нче күнегүдәге тексттан баш кисәкләре (иясе дә, хәбәре дә) булган җөмләләрне табыгыз, тәрҗемә итегез.

**7.** Бирелгән җөмләләрне үрнәк буенча киңәйтеп языгыз.

Ү р н ә к: Минем ял көнем. Минем ял көнем булмый. Минем ял көнем кайчакта булмый. Минем ял көнем кайчакта булмый, чөнки эшем күп.

1. Буш вакыт. 2. Мин яратмыйм.

**8.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: балалар буш вакытларын ничек уткәрәләр?



**9.** Җөмләләрне укыгыз. Ия белән хәбәр арасында тыныш билгесен языгыз.

1. Китап уку — файдалы эш.
2. Бакчада эшләү — әти-әнигә зур ярдәм.
3. Вакытны дөрес файдалану — тәрбиялелек билгесе.
4. Туктаусыз компьютерда уйнау — вакытны файдасыз уздыру.

**10.** Диалогны үзара сөйләшегез.

— Альбина, син сәяхәт итәргә яратасыңмы?
— Әлбәттә, яратам.
— Синең кайларда булганың бар?

— Буш вакыт каникулларда була инде. Каникул вакытында әти-әниләр белән Мәскәүгә бардык.

— Кайларда булдыгыз?

— Мәскәүдә Кызыл мәйданда булдык.

— Ошадымы?

— Бик ошады.

**11.** Рәсемнәргә карагыз, Татарстандагы сәяхәт урыннарын өйрәнегез. Алар турында Интернеттан материаллар туплап, сөйләргә өйрәнегез.



Казан Кремлен «Казанның үзеге йөрәге» дип атыйлар. Монда атаклы Сөембикә манарасын, Благовещение соборын, Кол Шәриф мәчетен күрергә була.



Болгар шәһәре Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы була. Ул бүген ачык һавадагы иң зур тарихи музей.



Свияжск шәһәренә 1551 нче елда Явыз Иван нигез сала. Хәзер ул Болгар кебек үк ачык һавадагы музей булып тора.

## 41–43 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Теркәгечләр (союзы)**

**Тезүче** (сочинительные) һәм **ияртүче** (подчинительные) теркәгечләр була.

**Тезүче теркәгечләр**

1. **Җыючы** (собирательные): һәм, да/дә, та/тә, янә, ни һ.б.
2. **Каршы куючы** (противительные): ләкин, ә, тик, әмма һ.б.
3. **Бүлүче** (разделительные): я, яки, яисә, әле, әллә һ.б.

**Ияртүче теркәгечләр**

Чөнки, әгәр, гүя, ягъни, ки, гәрчә һ.б.

**2.** Бу теркәгечләрне тиешле баганаларга урнаштырыгыз.

Һәм, ләкин, әмма, я, яисә, ә, да/дә, та/тә, тик, исә, яки.

| Җыючы | Каршы куючы | Бүлүче |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Минем буш вакытым аз, чөнки ... .
2. Буш вакытым күп, шуңа күрә ... .
3. Буш вакытта нишләргә белмим, чөнки ... .
4. Буш вакытны файдалы үткәрәм, ләкин ... .

**4.** Җөмләләрне язып бетерегез. Җөмлә эчтәлеге буенча бер-берегезгә сораулар бирегез, үзара сөйләшегез.

1. Әгәр минем буш вакытым булса, ... .
2. Минем буш вакытым аз булса, ... .
3. Минем буш вакытым күп булса, ... .
4. Буш вакытта нишләргә белсәм, ... .
5. Буш вакытны файдалы үткәрсәм, ... .

**5.** Диалогны укыгыз, үзара сөйләшегез. Алмаз дөрес эшләгәнме?

— Алмаз, кичә өйдә нишләдең?
— Дәресләремне әзерләдем дә чаңгы шуарга чыктым.
— Кем белән шудың?
— Дусларым белән шудым.
— Урамда суык иде, туңмадыгызмы соң?
— Юк, мин кышкы табигатьне яратам, тиз хәрәкәтләнгәч туңмадык.

**6.** Диалогларны укыгыз, аларны сәхнәләштерегез. Сезгә кайсысы ошый?

1. — Наилә, буш вакытың булса, син нишлисең?
— Буш вакытым булса, Интернетка керәм, дусларым белән очрашам.
— Минем буш вакытым бар. Әйдә дискотекага барабыз.
— Әйдә, мин риза.

2. — Айзат, ял көне кич нәрсә эшлисең?
— Белмим әле.
— Әйдә кинога барабыз.
— Әниләр рөхсәт итсә, әлбәттә, барабыз.

3. — Петя, әйдә китапханәгә барабыз.
— Син китап укырга яратасыңмыни?
— Әйе, мин, буш вакытым булса, китап укыйм.
— Ә мин телевизор карарга яратам.

**7.** Сезнең буш вакытыгыз бармы? Сезнеңчә, буш вакыт нәрсә ул? Сез аны ничек үткәрәсез? Төркемнәрдә фикер алышыгыз. Дәфтәрегезгә языгыз.

**8.** Спросите у друга:

— любит ли он ходить в театр;
— когда он был в театре;
— с кем он ходит в театр;
— какие спектакли он смотрел;
— понравился ли ему спектакль ;
— как играли артисты.

**9.** Поговорите с другом.

1. — Петя, вакытың ничек үтте?
— Файдалы үтте.
— Ни өчен файдалы дисең?
— Чөнки яхшы эшләр эшләдем.

2. — Син буш вакытта нишлисең?
— Буш вакытта Интернетка керәм, кызыклы материаллар укыйм.
— Ә мин буш вакытта футбол, баскетбол уйнарга яратам. Без бүген дә малайлар белән җыелабыз (собираемся). Киләсеңме?
— Уйлап карармын.

**10.** Позови друга после уроков пойти:

— в парк;
— в театр;
— в музей;
— на выставку (күргәзмә);
— на стадион;
— в поход.

Ярдәмгә — плакатлар!

# 44–46 нчы дәресләр

1. **Исегезгә төшерегез!**

**Имя действия (исем фигыль)**

**Имя действия** — это форма глагола, которая имеет признаки глагола и имени существительного. Образуется присоединением к основе аффиксов **-у/-ү**: кайту, китү, әзерләү, керү.

2. Буш вакытны файдалы һәм файдасыз үткәрергә мөмкин. Фикерегезне таблицага языгыз, исем фигыльләр кулланыгыз.

| Файдалы үткәрү | Файдасыз үткәрү |
|---|---|
| ... | ... |

3. **Исегездә калдырыгыз!**

Своё мнение можно выразить следующим образом:

1. Риза. — Согласен.
2. Мин тулысынча риза. — Я полностью согласен.
3. Мин өлешчә риза. — Я частично согласен.
4. Юк, минем уйлавымча, алай ук түгел. — Нет, по-моему, это не совсем так.
5. Юк, мин риза түгел (мин килешмим). — Нет, я не согласен.
6. Әйе, минемчә, бу бик дөрес. — Да, это, по-моему, совершенно правильно.
7. Мин дә шулай уйлыйм. — Я тоже так думаю.
8. Әйе, бу шулай. — Да, это так.

4. Текстны укыгыз. Күрше апа соравына сез ничек җавап бирерсез?

Эштән кайтканда, мине күрше апа туктатты. Эскәмиядә яшьләр тәмәке тартып утыралар иде. Күрше апа болай диде:

«Менә бу малайлар көнозын шушында утыралар, тәмәке тарталар, кычкырып-кычкырып көләләр, тирә-якка төкерәләр. Аларның эшләре юкмы әллә? Күпме вакытлары тәмәке тартып кына уза. Минемчә, бу бер дә әйбәт түгел. Ә синеңчә?»



**5.** Нокталар урынына үз фикерегезне белдергән сүзләрне өстәп языгыз.

1. ... , күрше апа хаклы.
2. ... , эскәмиядә тәмәке тартып утыру әйбәт түгел.
3. ... , тирә-якка төкерү — әдәпсезлек билгесе.

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез, сораулар куегыз, үзара сөйләшегез.

1. Эскәмиягә утырып ял итәргә була, ләкин ... .
2. Тәмәке тарту — начар гадәт, чөнки ... .
3. Эскәмия — ял итү урыны, шуңа күрә ... .
4. Буш вакытны дөрес файдаланырга кирәк, чөнки ... .
5. Малайларга күңелле булды, ә ... .
6. Малайлар яхшы ял итмәделәр һәм ... .
7. Ул тәмәке тартмый, буш вакытында спорт түгәрәгенә йөри, шуңа күрә ... .

**7.** Иптәшегез белән аның ял итүе турында схема буенча сөйләшегез, кереш сүзләрне кулланыгыз.

1.
— сорау
— җавап
— киңәш
— килешмәү
— аңлату
— килешү

2.
— сорау
— җавап
— сорау
— дәлилләү
— килешү

**8.** Укыгыз, фикерләшегез, нәтиҗә ясагыз.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы кисәтүенчә, ел саен дөньяда тәмәке тарту аркасында 2 миллион кеше авырып үлә.

**9.** 4 нче күнегү эчтәлеге буенча күрше апаның соравына җавап языгыз.

## 47 нче дәрес

**1.** Сүзтезмәләрнең һәм сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз.

Асылынып бара, шаярып йөри, ябышып бара, егетлек, өлгерлек, ялгыш, ялгышкан, култык таягы.

**2.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз, транскрипция билгеләре белән языгыз.

| | | |
|---|---|---|
| куркак | | ялгыш |
| дөрес | ? | кыю |
| тыйнак | | эшчән |
| ялкау | | чая |

**3.** Сүзләргә кушымчалар өстәп, яңа сүзләр ясагыз, тәрҗемә итегез. Ул сүзләр белән җөмләләр төзегез.

| | |
|---|---|
| егет | -лык |
| өлгер | -лек |
| батыр | |
| көчле | |
| тәртипсез | |

**4.** Җөмләләрдән исем фигыльләрне табыгыз, ия белән хәбәрне билгеләгез.

1. Трамвайга асылынып бару — тәртипсезлек. 2. Трамвайга асылынып бару көчлелек түгел. 3. Трамвайга асылынып бару — бушка вакыт үткәрү. 4. Әнигә ярдәм итү — өлгерлек.

**5.** Фигыльләрне тәрҗемә итегез. Үрнәктәгечә үзгәртеп языгыз.

Ү р н ә к: Бас — баскан — басып.
Саклан, асылын, шаяр, ябыш, ярыш, атла, ялгыш.

**6.** 5 нче күнегүдәге үзгәртелгән фигыльләрне нокталар урынына куеп укыгыз, җөмләләр төзегез.

… йөри, … атлый, … килә, … бара, … сөйләшә, … баса.

**7.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп укыгыз, җөмләләрнең ия белән хәбәрен атагыз.

1. Без, трамвайга асылынып, шаярып … . 2. Без бу эшне егетлек, өлгерлек дип … . 3. Бер аяк белән басып, бер кул белән тотынып … идек. 4. Без вакытны бушка … , әнигә эштә ярдәм … .

**8.** Посоветуйте другу:

— не цепляться за трамвай;
— не баловаться в транспорте;
— осторожно выходить из транспорта;
— быть внимательным на дороге.

## 48–50 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укыгыз. Малай кайчан сакланып атлый башлаган?

**Ялгыш адым**

Трамвайга асылынып
Йөргән чакта, шаярып,
Уйлагандыр — егетлек,
Өлгерлек бу, чаялык!

Бер аяк белән баскан,
Бер кул белән ябышкан.
Бик тә хәтәр ярышкан,
Бик тә хәтәр ялгышкан…



Калган ялгыш адымда
Ялгыш баскан аягы:
Сакланып кына атлый
Хәзер култык таягы...

Ш.Галиев

**чаялык** — лихость
**култык таягы** — костыль
**шаярып** — шутя
**хәтәр** — опасно
**асылынып** — повиснув
**өлгерлек** — ловкость

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[йа°зы̆лға́н], [бŏзŏлға́н], [йэ̆гэтлэ́к], [өлгөрлө́к], [йа°бы̆шқа́н], [йорт], [йа°ры̆шқа́н], [йа°лғы̆шқа́н], [қулты́қ].

**3.** Бу раслаулар белән килешәсезме? Төркемнәрдә фикерләшегез.

1. Трамвайга асылынып бару — өлгерлек.
2. Трамвайга асылынып бару — тәртипсезлек.
3. Трамвайга асылынып бару — көчлелек.
4. Трамвайга асылынып бару — бушка вакыт үткәрү.
5. Трамвайга асылынып бару — егетлек.
6. Әнигә эштә ярдәм итү — өлгерлек.
7. Әнигә эштә ярдәм итү — көчлелек.
8. Әнигә эштә ярдәм итү — егетлек.

**4.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Шәүкәт Галиев ни өчен шигырьне «Ялгыш адым» дип атый?
2. Ялгыш адым нинди нәтиҗәгә китерә?
3. Өлгерлек, чаялыкны сез нәрсәдә күрәсез?

**5.** Егетлек нәрсә ул? Сорауларга төркемнәрдә фикер алышыгыз.

1. Буш вакытта дискотекага йөрү егетлекме?
2. Дачада җир казу, эш эшләү егетлекме?
3. Сыра эчеп, яшьтәшләрең белән урамда йөрү егетлекме?
4. Кызларга авыр эштә булышу егетлекме?
5. Классны җыештыруда катнашу егетлекме?
6. Спорт белән шөгыльләнү егетлекме?

7. Кызларга төрле кушаматлар тагу егетлекме?
8. Подъезд стенасына төрле рәсемнәр ясау егетлекме?

**6.** Төркемнәрдә 5 нче күнегү эчтәлеге буенча фикер алышыгыз. «Бездәге үрнәк сыйфатлар» темасына чыгыш әзерләгез.

**7.** Узнайте у друга (подруги):

— как он (она) проводит свободное время;
— есть ли у него (неё) сегодня свободное время;
— куда он (она) сегодня идёт;
— пойдёт ли он (она) в библиотеку, на дискотеку, в спортзал, на стадион.

**8.** Допустим, вас пригласили на дискотеку. Откажитесь и объясните причину.

**9.** Рәсемнәргә карап, буш вакытны файдалы үткәрү турында сөйләгез. Төркемнәрдә фикер алышыгыз, чыгыш әзерләгез.











**10.** Предложите Азалии:

— подружиться;
— встретиться;
— вместе ходить в школу;
— вместе готовить уроки;
— вместе играть в теннис;
— вместе идти в театр.

**11.** Спросите друга:

— готовил ли он сегодня домашнее задание;
— идёт ли он на стадион;
— нравится ли ему спорт;
— на какой кружок он ходит.

**12.** Как скажете, если ваш друг помог вам:

— готовить уроки;
— решить задачу;
— составить диалог;
— написать сочинение?

**13.** Как пригласите подругу:

— вместе танцевать, петь, играть на гитаре;
— на дискотеку (на концерт, в театр, в кино)?

## 51 нче дәрес

**1.** Нокталар урынына тиешле тартым кушымчаларын куеп языгыз.

| | |
|---|---|
| минем йорт..., сүз... | безнең йорт..., сүз... |
| синең йорт..., сүз... | сезнең йорт..., сүз... |
| аның йорт..., сүз... | аларның йорт..., сүз... |

**2.** Сүзләрне укыгыз, нинди аффикслар ялганганын әйтегез, аларны аерып языгыз.

Подъездына, тактасын, сүзләренә, бабаларына, күзенә, исемнәрен, эшләреннән, дошманнарына.

**3.** Сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез. Тартымлы исемнәрне таблицага языгыз.

| Б.к. | И.к. | Ю.к. | Т.к. | Ч.к. | У.-в.к. |
|---|---|---|---|---|---|
| ... | ... | ... | ... | ... | ... |

Сүзтезмәләр: йортның подъездына, сыйныф тактасын, аларның сүзләре, малайларның автографларында, бабаларының эшен, дошман күзенә, үз исемнәрен, мәктәп укучыларының.

**4.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| матур | | бетерә |
| аңгыра | | мактый |
| башлый | ? | акыллы |
| дус | | ямьсез |
| хурлый | | боза |
| ясый | | дошман |

**5.** 3 нче күнегүдәге тартымлы исемнәр белән җөмләләр төзегез.

## 52–54 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез. Алар сезгә шигырьне аңларга ярдәм итәр.

Подъездына, язылмаган, бозылмаган, бутыйлар, мактамыйлар, боргалый, калдыра, дәвам итәләр.

**2.** Шигырьне укыгыз. Подъезддагы язулар белән рейхстагтагы язулар берме?

### Подъезддагы язулар




Безнең йортның подъездына
Ни генә язылмаган,
Ничек кенә бозылмаган,
Ни генә сызылмаган...
Бутыйлардыр бу малайлар,
Ахры, класс тактасын.
Ләкин мондый сүзләр өчен
Аларны кем мактасын?
Юк шул, мондый язу өчен
Бер кеше дә мактамас.
Сүзләре нинди бит әле:
«Штирлиц», «Тарзан», «Фантомас»...
«Булдылар монда кичә
Гөлнур + Халисә»,
«Гөлназ + Мөхәммәт = мәхәббәт».
«И Нургали, Нургали
Башын-күзен боргалый».
«Дәниф — дурак»,
«Илгиз — дуңгыз»,
«Мифтахетдин — аңгыра»...
Малайлар әнә шундыйрак
Автографлар калдыра.
Хәтта аннан да «матуррак»
Сүзләр язып китәләр.
Имештер, бабаларының
Эшен дәвам итәләр...
Аларның бабалары да,
Кереп дошман күзенә,
Исемнәрен язып кайткан
Рейхстагның үзенә!




Р. Миңнуллин

**ни генә язылмаган** — что только не написано
**ничек кенә** — как только

**бозылмаган** — не испорчено
**имештер** — дескать
**бутыйлардыр** — путают, наверное
**аңгыра** — глупый
**мәхәббәт** — любовь

**3.** Бу җөмләләрнең эчтәлеге шигырь эчтәлегенә туры киләме?

1. Малайлар подъездга берни дә язмаган.
2. Малайлар подъезд стенасын бозганнар.
3. Подъездда начар сүзләр язылмаган.
4. Подъездның буяулары бозылган.
5. Малайлар бер-берсе турында начар сүзләр язганнар.

**4.** Текст эчтәлегенә таянып, җөмләләрне дәвам итегез.

1. Безнең йортның подъездында ... . 2. Подъезд стенасына ни генә ... . 3. Малайлар шундый автографлар ... . 4. Имештер, бабаларының ... . 5. Бабалары рейхстаг стенасына ... .

**5.** Шигырьнең соңгы дүрт юлын укыгыз. Сез аны ничек аңлыйсыз? Рейхстагка Кызыл Армия солдатлары язган сүзләрне Интернеттан табыгыз. Җиңү көне турында сез нәрсәләр сөйли аласыз?

**6.** Как скажете о том, что:

— нельзя писать на стенах в подъезде;
— за слова, написанные на стенах в подъезде, никто не похвалит;
— нельзя оставлять свои автографы везде?

**7.** Схемалар буенча диалоглар төзегез.

1. — сорау
— җавап
— тәкъдим
— килешү

2. — сорау
— каршы сорау
— аңлату
— килешү

Т е м а л а р: Подъезддагы язулар. Подъезддагы чисталык.

8. Посоветуйте другу:

— не писать на стенах в подъезде;
— не портить стены в подъезде;
— не хвастаться плохими поступками;
— не чиркать на стенах в подъезде;
— не мусорить в подъезде;
— помогать пожилым людям, живущим в вашем подъезде.

9. Бу раслаулар белән килешәсезме? Фикерләрегезне бер-берегезгә дәлилләп (аргументируя) сөйләгез.

1. Подъезд стеналарына яхшы сүзләр язарга ярый.
2. Подъезд стенасына рәсем ясаган өчен мактыйлар.
3. Кеше автографын бар җирдә дә калдыра ала.
4. Подъезд стенасы сыйныф тактасы түгел, анда язарга ярамый.

10. Әйтик, сезнең подъезд чисталык буенча беренче урынны алды. «Безнең йортның подъезды» дигән темага кечкенә хикәя төзегез.

11. Үзегез язган хикәяне төркемнәрдә бер-берегезгә сөйләгез.






# ӨЛКӘННӘР ҺӘМ КЕЧКЕНӘЛӘР



## 55–57 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен өйрәнегез.

Өлкәннәр — старшие, взрослые, кечкенәләр — младшие, оныклар — внуки, уллар — сыновья, һәркем — каждый, һәрвакыт — всегда, яшьтәшләр — сверстники, игътибарлы — внимательный, ярдәмчел — отзывчивый, әдәпле — воспитанный, тактичный, хөрмәт итә — уважает.

**2.** Дустыгыз белән сөйләгез.

— Сезнең гаиләдә кемнәр бар?
— Әбием, бабам, әнием, әтием, абыем бар.
— Әтиең кайда эшли?
— Әти заводта эшли.
— Кем булып эшли?
— Токарь булып эшли.

**3. Исегезгә төшерегез!**

**Ия, хәбәр** — җөмләнең **баш кисәкләре. Аергыч** (определение), **хәл** (обстоятельство), **тәмамлык** (дополнение) — җөмләнең **иярчен кисәкләре** (второстепенные члены предложения).

**4.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Определение (аергыч)** — второстепенный член предложения, который обозначает качество, свойство, количество или принадлежность предмета и отвечает на вопросы **какой? чей? который?** Определение подчиняется любому члену предложения, выраженному именем существительным или другой частью речи в роли имени существительного.

Исемне ачыклап килеп, **нинди? ничәнче? кайсы? кемнең? нәрсәнең?** сорауларына җавап булган җөмлә кисәге **аергыч** дип атала. Барлык сүз төркемнәре дә аергыч була ала.

Мисаллар: Минем тугрылыклы дустым бар. Ләйсәннең көндәлеге өстәлдә ята. Мин җиденче сыйныфта укыйм. Кызларга игътибарлы егетләр ошый.

**5.** Җөмләләрне укыгыз, аергычларны билгеләгез.

1. Кешеләргә әдәпле эндәшергә кирәк. 2. Тәрбияле кешене һәркайда яраталар. 3. Миңа тырыш кешеләр ошый. 4. Мин синдә яхшы дуслар телим. 5. Әдәп төбе — матур гадәт. 6. Әнисе улына тыныч йокы теләде. 7. Тәмле телле булу өчен нишләргә кирәк?

**6.** Бирелгән сыйфатларның антонимнарын табыгыз, алар белән җөмләләр төзеп языгыз. Җөмләләрдә аергычларны билгеләгез, аларга сораулар куегыз.

Әдәпле, гади, өлкән, җылы, күңелле, тәмле, кечкенә, тәртипсез.

**7.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемәләрен сүзлекләрдән табыгыз.

Өлкәннәр, кечкенәләр, оныклар, уллар, мөнәсәбәт, үзләренчә, һәркем, яшьтәшләр, аралашу.

**8.** 6 нчы күнегүдәге сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзеп языгыз. Диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**9.** Бирелгән исемнәр белән исем+исем конструкцияләре төзегез.

И с е м н ә р: бабай, абый, әни, әти, әби, кыз, апа, кыз, ир, хатын, ат.

**10.** 7 нче сыйныф укучысы Илдар язган хатны укыгыз. Сез аның белән килешәсезме?



Өлкәннәр белән кечкенәләрнең үзара мөнәсәбәте һәрвакыт күп сорау тудыра. Өлкәннәр дип әби-бабайларга, әти-әниләргә, апа-абыйларга әйткәнне сез беләсез. Ә кечкенәләр — өлкәннәрнең кызлары, уллары, оныклары. Шунысы кызык: кечкенәләр үзләренчә яшәргә тели. Алар күбрәк уйнарга, яшьтәшләре белән очрашырга, дискотекаларга йөрергә, музыка тыңларга яраталар. Ә өлкәннәр моңа риза түгел. Өйдә күбрәк булсаң, булышсаң, аларны тыңласаң, син әйбәт. Әйе, һәркем үзенчә хаклы. Әлбәттә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә кирәк. Ләкин иптәшләр белән аралашу шулкадәр рәхәт, кайчагында өйгә кайту да онытыла... Кечкенә чакта төрле ялгышулар була шул инде.

Әбием: «Һәр эштә тәртип булырга тиеш», — ди. Бәлки, ул хаклыдыр?..

«Сабантуй» газетасыннан





**үзара мөнәсәбәт** — взаимоотношения
**яшьтәшләр** — ровесники

**11.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Өлкәннәр дип без ... . 2. Кечкенәләр дип без ... . 3. Кечкенәләр күбрәк уйнарга, ... . 4. Өйдә күбрәк булсаң, булышсаң, аларны тыңласаң, ... . 5. Әлбәттә, өлкәннәрне ... .

**12.** Ноктала урынына кем күбрәк сүзләр яза ала? Җөмләләргә сораулар куегыз, үзара сөйләшегез.

1. Кечкенәләр ... ярата. 2. Өлкәннәр ... куша.

**13.** Дуслар белән очрашу, дискотекага бару, музыка тыңлау турында диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**14.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез.

— Коля, сезнең гаиләдә кемнәр бар?
— Әбием, бабам, әнием, әтием, абыем бар.
— Алар сезнең белән яшиме?
— Әйе, әбием бик мәрхәмәтле (добрый) кеше, ә бабам усалрак.
— Әниең кайда эшли?
— Кибеттә.
— Кем булып эшли?
— Сатучы.

**15.** 14 нче күнегүдәге диалогка охшаш диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

## 58–59 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Дополнение (тәмамлык)** — второстепенный член предложения, который выражает различные значения объекта, иногда и исполнителя, отвечает на вопросы косвенных падежей существительных, местоимений.

2. Җөмләләрдән тәмамлыкларны табыгыз, аларга сораулар куегыз.

Дополнение подчиняется любому члену предложения, выраженному словами со значением действия, состояния или признака.

Эш-хәрәкәт белдерә торган сүзгә ияреп килгән һәм аның үтәлүенә бәйле предметны, затны күрсәткән иярчен кисәк **тәмамлык** дип атала.

Ул **кемгә? нәрсәгә? кемне? нәрсәне? нәрсә белән? кем белән? нәрсә турында? кем турында? кемнән? нәрсәдән?** сорауларына җавап бирә.

Мисаллар:

Мин хат язам.
Мин әнигә хат язам.
Мин хатны почтага салам.
Мин бәйрәм турында хат язам.
Мин почтадан посылка алып кайтам.

3. Җөмләләрдән тәмамлыкларны табыгыз, аларга сораулар куегыз.

1. Кларага яшьтәшләре белән дөрес аралашырга кирәк.
2. Тәрбияле кешеләр яхшы кешедән үрнәк алалар.
3. Өлкәннәрне һәрвакыт хөрмәт итәргә кирәк.
4. Мәктәбебездә әдәплелек турында сыйныф сәгатьләре еш була.

4. Как скажете о том, что:

— друг другу всегда нужно помогать;
— воспитанный человек уступает место старшим;
— вы хотите прочитать книгу о правилах этикета?

5. Хәләф Гардановның әдәплелек турындагы хикәясен укыгыз. Кем юл бирергә тиеш? Хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

### Ничек кирәк?

Тар басмада Илдар белән Ирек очраштылар. Малайларның берсе зур, икенчесе кечерәк. Илдарга — унике яшь,

Ирекка — сигез. Берсе дә юл бирми боларның. Илдар: «Мин өлкән, ул мине хөрмәт итәргә тиеш», — дип уйлый, ә Ирек: «Мин кечкенә, ул кечкенәләргә юл бирергә тиеш», — ди.

Мондый очракта нишләргә? Кем юл бирергә тиеш?



**6.** Тексттан аергыч һәм тәмамлыкларны табыгыз, аларга сораулар куегыз.

**7.** Илдар белән Ирекка нинди киңәшләр бирер идегез?

**8.** Илдар яки Ирек әдәпле малайлар булсалар, алар арасында нинди сөйләшү булыр иде? Дәфтәрегезгә языгыз.

**9.** Мәхмүт дөрес эшләдеме?

Мәхмүт мәктәпкә чапты. Урамда ул бер ападан:

— Вакыт күпме? — дип сорады.

Апа сәгатен карап әйткәнче, Мәхмүт ашыгып китеп барды. Уйлап карагыз әле: Мәхмүт ничә хата ясады?

Х.Гардановтан

**10.** Мәхмүт хата ясамаса, хикәя ничек үзгәрер иде? Дәфтәрегезгә языгыз.

## 60–61 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Обстоятельство (хәл)** — второстепенный член предложения, который обозначает место, время, причину, цель, условие, образ действия и отвечает на вопросы **где? когда? почему? с какой целью? при каком условии? как? сколько?** и другие.

Билгенең билгесен, эш-хәрәкәтнең үтәлү урынын, вакытын, сәбәбен, максатын, шартын, рәвешен, күләмен белдереп, **кайда? кайчан? ни өчен? нинди максат белән? нишләсә? ничек? күпме?** сорауларына җавап биргән иярчен кисәк **хәл** дип атала.

М и с а л л а р: Машинабыз бик тиз бара. Җәен без бик яхшы ял иттек.

**2.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез. Җөмләләрдән хәлләрне табыгыз.

1. — ... ?
— Әйе, без Оксана белән бергә мәктәптә укыйбыз.
— ... ?
— Без бергә музыка тыңлыйбыз, китапханәгә йөрибез, дусларга барабыз.
— Сез кайчан таныштыгыз?
— ... .

2. — Әнием, бүген дискотекага барыйм әле.
— ... ?
— Оля, Наташа, Алсу, Рафаэль бара.
— ... ?
— Озак тормыйбыз. Кич сәгать тугызда өйдә булам.
— ... .

3. — Ләйсән, әйдә кич дискотекага барабыз.
— Оля, минем өйдә эшем бар. Әни өй җыештырырга кушты.
— ... .

— Бик зур рәхмәт, мин сине көтәм.
— ... .
— Ярый, ярый. Үзем җыештыра торам.

**3.** Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзеп языгыз. Җөмлә кисәкләрен билгеләгез.

1. Яшьтәшләр, очрашырга, без, еш, белән, яратабыз.
2. Һәрвакыт, тиеш, өлкәннәрне, хөрмәт, кечкенәләр, итәргә.
3. Тырыш, минем, ирешә, шуңа, күрә, әтием, максатына, кеше.
4. Өлкәннәр дә, яшәргә, балалар да, үзләренчә, телиләр.
5. Өлкән, автобуста, урын, бирергә, кешеләргә, кирәк.

**4.** Әйтик, сез түбәндәге ситуацияләрдә калдыгыз, ди. Диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.



1. Сезне иптәшләрегез дискотекага чакырды, һәм сез риза булдыгыз. Өйгә кайткач, әниегез сезгә кунаклар килүен, аңа ярдәм итәргә кирәклеген әйтте. Әгәр әниегез сезне дискотекага җибәрмәсә, нинди сөйләшү булыр:
а) әниегез һәм сезнең арада;
ә) иптәшләрегез белән сезнең арада?



2. Әниегез сезгә эш куша һәм тиз эшләп бетерү шартын (условие) куя. Сез бу хакта иптәшләрегезгә әйтәсез, алар сезгә булышырга теләк белдерә. Нинди сөйләшү булыр:
а) әниегез белән сезнең арада;
ә) яшьтәшләрегез белән сезнең арада?

**5.** «Ярдәмләшеп яшәү күңелле» темасына хикәя төзегез.

## 62–64 нче дәресләр

**1.** Җөмләләрнең дөрес тәрҗемәсен икенче төркемнән табыгыз.

1. Өлкәннәрне хөрмәт итү — тәрбиялелек билгесе. Ата-ананың баланы яратуы бик көчле була. Ата-ананы хөрмәт итү — иң төп бурыч. Ялгышулар булырга мөмкин. Миңа музыка тыңлау ошый. Мәктәптә рәсем ясау конкурсы булды.

2. Уважение к взрослым — признак воспитанности. Могут быть заблуждения. Мне нравится слушать музыку. В школе был конкурс рисунков. Любовь родителей к ребёнку бывает очень сильной. Уважение родителей — это основная обязанность.

**2.** Җөмләләрдән исем фигыльләрне табыгыз, килешләрен билгеләгез һәм аларга сораулар куегыз.

1. Өлкәннәрне тыңлау зыян итми. 2. Табигатьне саклау — һәр кешенең изге бурычы. 3. Исәнләшүнең үз кагыйдәләре бар. 4. Иптәшләре белән очрашуга ул шат. 5. Яшьтәшләре белән очрашуны ул көтеп алды. 6. Дуслар белән очрашу күңелле. 7. Мәктәптә өлкәннәр көне үткәрү — яхшы традиция.

**3.** Нокталар урынына туры килгән исем фигыльләрне өстәп языгыз.

1. Өлкәннәрне ... — һәркемнең бурычы. 2. ... сәламәтлеккә зарарлы. 3. Классташлары белән урманга ... Серёжага ошады.

И с е м ф и г ы л ь л ә р: бару, тәмәке тарту, хөрмәт итү.

**4.** Сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең тәрҗемәсен табыгыз.

Күп, күптән, белә, белгән кеше, бик, зуррак, шул, шуны.

**5.** Шигырьне укыгыз. Иң зур кеше кем?

### Иң зур кеше

Күпне белгән кеше —
Ул зур кеше була...
Күптән-күптән белгән —
Бик зур кеше була.
Бик зур кешегә дә
Тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
Зуррак кеше булмый,
Шуны белгән кеше
Иң зур кеше була.

Р.Мингалим

**күптән-күптән** — давным-давно
**тиң** — равный
**булмый** — не бывает

**6.** Сораулар буенча бер-берегез белән сөйләшегез.

1. Ни өчен «күпне белгән кешене» зур кеше дияргә мөмкин?
2. Ни өчен «күптән-күптән белгән кешене» бик зур кеше дибез?
3. Ни өчен әти-әнине хөрмәтләүче кеше — иң зур кеше?

**7.** Әйтик, берәү бик күп эшләде, баеды. Кибетләр тота, коттедж салды, ди. Ләкин әти-әнисен онытты, аларның хәлен белми башлады. Бу кешене зур кеше дип әйтеп буламы? Төркемнәрдә сөйләшегез.

**8.** Бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Һәр мәкальгә тормыштан мисаллар китерегез.

Олыласаң олыны,
Олыларлар үзеңне.

Ата-ананы тыңлаган адәм булган,
Тыңламаган әрәм булган (пропал).

**9.** 8 нче күнегүдәге мәкальләрнең эчтәлегенә карата кечкенә хикәяләр языгыз.

**10. Исегездә калдырыгыз!**

### Кисәкчәләр (частицы)

Частицы выражают отношение говорящего к действительности. Они придают отдельным словам и целым предложениям различные смысловые оттенки.

**Раслаучы** (утвердительные): бит, инде, ич.

**Инкяр итүче** (отрицательные): һич, түгел.

**Сорау** (вопросительные): -мы/-ме, -мыни/-мени.

**Чикләүче** (ограничительные): гына/генә, кына/кенә.

**Ачыклаучы** (уточнительные): нәкъ.

**Көчәйткеч** (усилительные): иң, сап-, кап-, ямь-, да/дә, та/тә.

**Билгесезлек** (неопределённые): әллә, -дыр/-дер, -тыр/-тер.

**Үтенү кисәкчәләре** (выражающие просьбу): -чы/-че.

### Правописание частиц

1. Усилительные частицы находятся перед прилагательными и наречиями: **иң ерак, иң җылы, кып-кызыл, сап-сары** и др.

Усилительные частицы **да/дә, та/тә, ук/үк** находятся после слова, которому придаются различные оттенки: Әлфия дә килде. Улым, хәзер үк кайтып җит!

2. Частицы **-дыр/-дер, -тыр/-тер, -чы/-че, -сана/-сәнә, -мы/-ме, -мыни/-мени** пишутся слитно и по закону сингармонизма: кайткандыр, киткәндер, килсәнә, әйтче, көтәсеңмени?

3. Ограничительные частицы **гына, генә, кына, кенә** пишутся раздельно и по закону сингармонизма: Ул гына килмәде. Әлфия генә кайтты.

**11.** Кисәкчәләрне билгеләгез, диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Әбием, минем ашыйсым килә, аш пешкәндер инде?
   — Аз гына көт, улым, хәзер пешә.

2. — Ишекне кем ачты, Анямы?
— Юк, Аня түгел. Ул мәктәпкә килмәде бит.
— Синме?
— Мин дә түгел. Алсудыр. Ул бүген беренче килде.

3. — Оля, тиз генә китапханәдән журнал алып кил әле.
— Китапханә эшлимени? Соң бит инде.
— Эшлидер, бар инде.

4. — Каян алдың бу кып-кызыл розаларны? Нинди матурлар!
— Иң матурларын сайладым. Бүләккә.
— Кемгә?
— Әнигә.

5. — Әбием, ашарга утыр инде, аш суына бит.
— Рәхмәт, кызым, тиз генә кулымны юам да утырам.

## 65–67 нче дәресләр

**1.** Яшьтәшегезнең тәрбиялелек турында фикерен укыгыз. Аны «Ялкын» журналына 14 яшьлек Гөлнара язып җибәргән.

Без иң беренче чиратта гаиләдә тәрбияле булырга тиеш. Әнисенә: «Мин киттем, кайчан кайтасымны белмим», — дигән яисә әтисенә: «Бүлмәдән чык, ишекне яп!» — дип әйткән баладан ни көтәсең?.. Андый бала, мөгаен (пожалуй), сыйныфташына: «Әй, юанкай (толстушка), дәфтәреңне бир!»— дип эндәшер. Үпкәләгән «юанай» ишетмәмешкә салышса



(если прикинется, что не слышала), «Кара, син саңгырау да икән әле», — дип көләр.

Кешеләргә ихтирамны, аралашу әдәбен гаиләдә тәрбияләмәсәләр, әдәплелек дәресләре генә ярдәм итмәс.



**2.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

**тәрбиялелек**
1) воспитанный 2) воспитанность 3) воспитывает

**әгәр**
1) но 2) если 3) да

**көләр**
1) смеются 2) посмеётся 3) будет смеяться

**үпкәләгән**
1) обиделся 2) обиженная 3) обидевшись

**3.** Текстның беренче җөмләсеннән ия белән хәбәрне табыгыз. Җөмләнең һәр кисәгенә сорау куегыз, җөмлә кисәкләрен билгеләгез.

**4.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Төркемнәрдә фикерләшегез. Үз фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән дәлилләгез (аргументируйте).

1. Без, иң беренче чиратта, мәктәптә тәрбияле булырга тиеш.
2. Без, иң беренче чиратта, гаиләдә тәрбияле булырга тиеш.
3. Без өйдә дә, урамда да, мәктәптә дә тәрбияле булырга тиеш.

**5.** Әйтик, сез дусларыгызга барырга җыенасыз. Өйдәге өлкәннәр белән сезнең арада нинди сөйләшү булыр? Диалоглар төзегез.

**6.** Җөмләләрне укыгыз. Төркемнәрдә аларның эчтәлеге турында сөйләшегез. Фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән раслагыз, дәфтәрегезгә языгыз.

1. Минем тәрбиялелегем үземә кирәк, чөнки, иң беренче чиратта, мин үзем өчен үзем җавап бирәм.
2. Бигрәк тә чит кешеләр алдында тәрбияле булырга кирәк, чөнки тәрбиясез күренсәм, миңа бигрәк оят була.
3. Кайбер кешеләр чит кешеләр алдында тәрбияле булалар, ә кеше күрмәгәндә төрле начарлыклар эшлиләр. Бу тагын да куркынычрак.

**7.** Тәрҗемә итегез.

1. Уважению к людям и этикету общения, в первую очередь, должны учить в семье.

2. Если уважению к людям и этикету общения не научить в семье, то ни один урок этики не поможет.

3. Мы должны уважать в первую очередь своих родителей.

**8.** Малай нәрсәдән көлгән? Аңа нинди киңәш бирерсез?

— Тагын пычранып кайткансың икән, — дип, әнисе улын орыша.

— Кичә, мин егылгач, Рәмзия көлгән иде. Бүген үзе дә егылды. Мин дә тәгәри-тәгәри көлдем, — дигән малай.



**тәгәри-тәгәри көлдем** — катался со смеху

**9.** Как скажете в этих ситуациях? Напишите в тетради.

1. Вам нужно идти к друзьям на день рождения. Вы собираетесь возвращаться только вечером. Сообщите об этом маме.

2. Как скажете, что у вас сегодня был урок этики?

**10.** Поговорите с другом.

— Сезнең гаиләдә кемнәр бар?
— Әбием, бабам, әнием, әтием, абыем бар.
— Әтиең кайда эшли?
— Әти заводта эшли.
— Кем булып эшли?
— Токарь булып эшли.
— Син өйдә нинди эшләр эшлисең?
— Савыт-саба юам, чүп чыгарам, тузан сөртәм, һәрвакыт урын җыям, идән себерәм, энемне карыйм, кибеткә барам.
— Ә ашарга пешерәсеңме?
— Юк, әни пешерә.

## 68–71 нче дәресләр

**1.** Шәүкәт Галиев биографиясен укыгыз.



Танылган балалар шагыйре Шәүкәт Галиев 1928 нче елда Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында туа. Ул — профессиональ язучы, шагыйрь. Шәүкәт Галиев балалар яратып укый торган шигырьләр иҗат итә. Ул шигырьләрендә тормышның кызыклы якларын сурәтли, көлдерә, яхшыны начардан аерырга өйрәтә.

**2.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез. Тәрҗемәсен сүзлекләрдән табыгыз.

Яхшылык, мактанчык, ялкау, гадел, әдәпле, тәрбиясез.

**3.** Сүзләрнең антоним парын әйтегез.

| | | |
|---|---|---|
| эшчән | | мактанчык |
| батыр | | саран |
| ак | | ямьсез |
| матур | ? | куркак |
| юмарт | | ялкау |
| әйбәт | | начар |
| тыйнак | | кара |

**4.** Сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз, җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| һәркем | | каждый (из них) |
| һәркайсы | ? | любой |
| һәркайда | | каждый (человек) |
| һәрберсе | | везде |

Шәүкәт Галиев шигырьләрен укы

**5.** Фигыльләрне таблицага урнаштырыгыз.

| Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Билгесез үткән заман хикәя фигыль |
|---|---|
| ... | ... |

Фигыльләр: эшләгән, ярдәм иткән, бирдем, диде, килгән, булды, чыгардым, хәл сораштым, санаган, кергән, төчкерде, әйттем.

**6.** Шигырьне укыгыз. Сәлим сезгә ошыймы?

**Тагын бер рәхмәт**

Кемгә яхшылык эшләгән,
Ярдәм иткән нихәтле —
Сәлимнең барсы санаулы,
Бөтенесе исәпле:



— Ике әби, бер бабайга
Трамвайда урын бирдем.
Ике әби һәм бер бабай
Һәркайсы «Рәхмәт!» диде.

Авылдан килгән өч апа
Адрес белмәгәч рәтләп,
Әйтеп бирдем. Менә сиңа
Булды янә өч рәхмәт!



Урам аркылы чыгардым
Тагын ике әбине:
Ике әби икесе дә
Ике рәт «Рәхмәт!» диде.



Күршенең хәлен сораштым,
Безгә кичә кич кергәч.
«Исәнлеккә-саулыкка!» — дип
Әйттем, абзый төчкергәч...

— Тырышкансың, рәхмәт, — дидем...
Сәлимгә ярап куйды:
— Тагын бер рәхмәт булды! — дип,
Шунда ук санап куйды...

Ш. Галиев

Рәхмәт турында шигырь тыңла

**бөтенесе исәпле** — всё учтено
**төчкергәч** — когда чихнул
**исәнлеккә-саулыкка** — на здоровье

**7.** Җөмләләрне шигырь эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Ул кичә күршенең хәлен сорашты. 2. Сәлим эшләгән яхшылыкларын санап бара. 3. Сәлим ике әбине юл аша чыгарды. 4. Әби белән бабайга трамвайда урын бирде.

**8.** Сәлим нинди яхшылыклар эшләде? Дәфтәрегезгә языгыз.

**9.** Сәлимне тыйнак малай дип әйтеп буламы? Төркемнәрдә сөйләшегез.

**10.** Посоветуйте Салиму не считать свои хорошие поступки, быть скромным.

**11.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнегез.

**Рәхмәт**

— Әхмәт, Әхмәт!
Тырысымны бирче рәтләп.
Әхмәт әйтә:
— Рәфгатькә әйт.
— Рәфгать, Рәфгать!
Тырысымны бирче рәтләп.
Рәфгать әйтә:
— Рәхмәткә әйт.
— Рәхмәт, Рәхмәт!
Тырысымны бирче рәтләп.
Бирде Рәхмәт шундук рәтләп.
— Рәхмәт, Рәхмәт!



М. Газизов

**тырыс** — корзина
**шундук** — тут же
**бирче рәтләп** — почини, пожалуйста

**12.** Сорауларга җавап бирегез.

1. **Рәхмәт** сүзе шигырьдә нинди мәгънәләр (значения) белдерә?
2. Рәфгать белән Әхмәт нинди малайлар?
3. Кызга тырысны кем рәтләп бирә?
4. Рәхмәткә нинди бәя бирергә була?

**13.** а) Как скажете о том, что вы:

— уступаете место в трамвае дедушке, бабушке, женщине с ребёнком;
— уступаете место в трамвае старшим?

б) Попросите братика уступить место старшим.

в) Подскажите брату, что надо уступать место старшим.

**14.** Төркемнәрдә сөйләшегез. Фикерләрегезне тормыштан мисаллар белән дәлилләгез. Сез бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

Үзеңне үзең мактама, кеше сине мактасын.

**15.** Попросите разрешения у мамы:

— пойти в кино с друзьями;
— пойти в гости к друзьям;
— отметить день рождения.

**16.** Как скажете о том, что вы:

— придёте домой вечером в 9 часов;
— вернётесь с велопохода завтра;
— можете прийти домой пораньше;
— в субботу пойдёте кататься на лыжах;
— будете отправлять смс?

# ТУГАН ЯГЫМ ТАБИГАТЕ



## 72–73 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен исегезгә төшерегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

туган як — ...
туган җир — ...
туган ил — ...

Ватан — ...
ил — ...
дәүләт — ...

**2.** Шигырьне укыгыз. Туган ягыбыз ни өчен күңелгә якын?

**Татарстаным**

Җәйге походка
Чыктык без тагын.
Көмеш суларың,
Зәңгәр урманың
Якын күңелгә,
Татарстаным!

Әй, матур да соң
Кама, Агыйдел,
Идел буйларың!
Әй, батыр да соң
Нефть табучы
Кыз һәм улларың,
Ачык һәм якты
Барыр юлларың,
Татарстаным!





Син — туган ягым,
Син — минем таңым,
Татарстаным!

И. Юзеев

**көмеш** — серебро, серебряный
**батыр** — храбрый
**таң** — заря

**3.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

[көмө́ш], [йа°кы́н], [а°ғидә́л], [туға́н], [ба°ты́р].

**4.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп укыгыз.

1. Татарстанның ... сулары, ... урманнары бар. 2. Татарстанның Кама, ..., ..., ..., ... кебек ... елгалары бар. 3. Татарстанның ... кыз һәм уллары бар. 4. Татарстанның барыр юллары ... һәм ... .

**5.** Җөмләләрне дәвам итегез, аларга сораулар куеп, үзара сөйләшегез.

1. Татарстан 4 елга иле, чөнки ... . 2. Иделгә Кама елгасы ... . 3. Кама елгасының борынгы исеме — ... . 4. Чулман елгасы ярларында ..., ... шәһәрләре бар. 5. Татарстанның климаты ... .

**6.** Түбәндәге сүзтезмәләр белән җөмләләр төзегез.

Калын урманнар, мул сулы елгалар, зур нефть ятмалары, кара алтын республикасы, Идел буенда.

**9.** Түбәндәге схемалар буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

1. — сорау
— җавап
— тәкъдим
— риза булу

2. — соклану (восхищение)
— риза булу
— сорау
— җавап

Т е м а л а р: Иделдә сәяхәт итү; табигать матурлыгы.

**8.** Шигырьдәге «Ачык һәм якты барыр юлларың, Татарстаным!» дигән юлларны сез ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез.

## 74–75 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Табигатебез турында Габдулла Тукай әйткән сүзләр белән сез килешәсезме?

### Безнең Татарстан

Минем туган җирем — Татарстан. Ул — иң бай, иң зур республикаларның берсе. Аның табигате төрле. Калын урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда пошилар, аюлар, төлкеләр, усал бүреләр дә очрый.

Татарстан аркылы зур елгалар ага. Идел, Чулман, Агыйдел, Нократ — Татарстанның иң зур елгалары.

Татарстан климаты уртача. Кышлары бик салкын, җәйләре бик эссе түгел. Габдулла Тукай табигатебез турында бик яратып язып калдырган:

Анда салкын вә (һәм) бик эссе түгел, урта һава.
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.
Ә нәрсә генә үсми бездә: бодай, арыш, кукуруз, карабодай, борчак, тары, чөгендер, көнбагыш.

Татарстанда өлгергән җиләк-җимешләр иң тәмлеләрдән санала. Аларны һәркем ярата.

Г. Бәшировтан

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

Табигать [таºбиғә́т], калын [қаºлы́н], Нократ [нŏқра́т], һава [һаºwá], төлке [төлкө́], Агыйдел [аºғидә́л], һәркем [һә́ркә̆м].

**3.** Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын табыгыз.

| | |
|---|---|
| бай — ... | салкын — ... |
| зур — ... | биек — ... |
| калын — ... | усал — ... |
| күп — ... | кыш — ... |

**4.** Түбәндәге раслауларның кайсысы дөрес? Дөрес раслауны дәфтәрегезгә языгыз.

1. Татарстан — иң кечкенә республикаларның берсе.
   Татарстан — иң зур республикаларның берсе.
2. Татарстанда калын урманнар да, тигез далалар да юк.
   Татарстанда калын урманнар да, тигез далалар да бар.
3. Татарстанда һава уртача.
   Татарстанда һава бик салкын.
4. Татарстанда җиләк-җимешләр генә үсә.
   Татарстанда бодай, арыш, карабодай үсә.

**5.** Предложите другу почитать книгу о Татарстане. Скажите о том, что он, прочитав эту книгу, узнает много интересного о природе Татарстана.

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Татарстанның табигате бай, шуңа күрә ... .
2. Татарстан — 4 елга иле, чөнки ... .
3. Татарстанның климаты уртача, шуңа күрә ... .

**7.** Спросите у друга:

— какие животные обитают в Татарстане;
— какие реки протекают через Татарстан;
— какие зерновые культуры растут в Татарстане.

**8.** Татарстан турындагы текстның эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

**9.** Поговорите с другом.

— Син кайда яшисең?
— Мин Татарстанда яшим.
— Татарстан нинди республика?
— Татарстан — зур, бай республика.

**10.** Таблицаны тутырыгыз.

| Татарстанның хайваннар дөньясы | Татарстанның кошлар дөньясы | Татарстанның файдалы казылмалары |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

## 76–78 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укыгыз. Сез нинди кызыклы мәгълүмат белдегез?

### Татарстан елгалары

Татарстанны «дүрт елга иле» дип йөртәләр. Татарстан аркылы Идел, Кама, Агыйдел, Вятка (Нократ) кебек зур елгалар ага.

Республикада тагын 500 ләп вак елга бар. Идел Татарстан территориясе буйлап 180 километр ага. Иделгә Кама елгасы кушыла. Бу урында Иделнең киңлеге 40 километрга җитә. Ә Кама елгасы Татарстан территориясе буйлап 380 километр ага. Аның борынгы исеме — Чулман. Кама ярларына зур шәһәрләр: Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Чистай урнашкан. Ык, Зәй, Мишә, Чирмешән, Зөя кебек елгалар да туган җиребезне бизи. Ык елгасының гомуми озынлыгы — 436 километр. Шуның 200 километрга якын өлеше Татарстан территориясеннән ага. Зөя елгасы бераз кыскарак — 377 километр. Болардан башка һәр авылның тәмле сулы салкын чишмәләре дә бар.



**чишмә** — родник
**киңлеге** — ширина
**кушыла** — впадает
**борынгы** — древний

Ык елгасы турында күбрәк бел

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

Вак [wa°қ], ага [a°ғá], борынгы [бŏрŏнғó], Алабуга [a°лабуғá].

**3.** Хикәядән географик атамаларны табыгыз. Аларны татарча-русча вариантлары белән дәфтәрегезгә языгыз.

Ү р н ә к: Идел — Волга, ...

**4.** Үрнәк буенча тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

Ү р н ә к: Татарстан аркылы — через Татарстан.
Идел аркылы; урман аркылы; урам аркылы; юл аркылы.

**5.** Хикәя буенча сорауларга җавап бирегез. Сораулар ярдәмендә үзара сөйләшегез.

1. Татарстанда нинди зур елгалар бар?
2. Татарстанда нинди вак елгалар бар?
3. Татарстанда Иделнең озынлыгы ничә километр?
4. Кама белән кушылган җирдә Иделнең киңлеге ничә километр?
5. Татарстанда Каманың озынлыгы ничә километр?

**6.** Бу раслауларның кайсысы дөрес?

1. Татарстан аркылы Идел, Днепр, Кама, Вятка, Агыйдел, Ык елгалары ага.
Татарстан аркылы Идел, Вятка, Чулман, Агыйдел, Ык елгалары ага.

2. Каманың борынгы исеме — Чулман.
Каманың борынгы исеме — Нократ.

3. Казан шәһәре Чулман ярына урнашкан.
Яр Чаллы шәһәре Чулман ярына урнашкан.

**7.** Русчага тәрҗемә итегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

Идел Чулманнан зуррак. — ... .
Агыйдел Чулманнан кечерәк. — ... .
Идел Нократтан озынрак. — ... .

# 79–80 нче дәресләр

**1.** Бирелгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, тәрҗемәләрен табыгыз.

Ел фасылы, бураннар, ләйсән яңгырлар, ябалак-ябалак карлар, сусыл җиләкләр, хәтфә үләннәр, исәпсез-хисапсыз чәчәкләр, шифалы яңгырлар, умырзая, гөрләвекләр, дөнья.

**2.** Текстны укыгыз. Автор һәр ел фасылын ничек сурәтли?









### И ямьле дә соң дөнья!

Һәр фасыл үзенчә ямьле, әйеме?

Кыш ябалак-ябалак булып яуган карлары, агач-куаклардагы ап-ак бәсләре, дуамал бураннары, тәрәзә пыялаларындагы карлы рәсемнәре белән матур.

Яз ләйсән яңгырлары, җылы яктан кайткан кошларның сайраулары, кәгазь көймәле гөрләвекләре, кар эрегәч чыккан чирәмнәре, умырзаялары белән гүзәл.

Җәй алсу, сусыл җиләкләре, хәтфә үләннәре, исәпсез-хисапсыз чәчәкләре, мул иген кырлары, шифалы, җылы яңгырлары белән соклангыч.

Көз... Әйе, көз дә — үзенә бер матур, гүзәл фасыл. Әллә Сентябрь малае, шукланып, агачлардагы алтынсу, сары яфракларны җиргә сибеп йөри... Әллә Җил малае әлеге яфраклар белән куышлы уйный.

И ямьле дә соң, күңелле дә соң дөнья! Шулай бит?!

Л. Лероннан

**куышлы уйный** — играет в догонялки
**соклангыч** — восхитительно, изумительно

**3.** Күп нокталар урынына сыйфатлар өстәп языгыз. Сүзтезмәләр белән җөмләләр уйлагыз.

... кар, ... бәс, ... чирәм, ... рәсем, ... җиләк, ... яңгыр, ... яфраклар, ... чәчәкләр.

**4.** Бу сурәтләүләр кайсы ел фасылына туры килә?

1. Ул ябалак-ябалак булып яуган карлары, ап-ак бәсләре, дуамал бураннары, тәрәзә пыялаларындагы карлы рәсемнәре белән матур.

2. Ул ләйсән яңгырлары, җылы яктан кайткан кошларның сайраулары, кәгазь көймәле гөрләвекләре, кар эрегәч чыккан чирәмнәре, умырзаялары белән гүзәл.

3. Ул алсу, сусыл җиләкләре, хәтфә үләннәре, исәпсез-хисапсыз чәчәкләре, мул иген кырлары, шифалы җылы яңгырлары белән сокландыгыч.

4. Ул алтынсу, сары яфраклары белән матур.

**5.** Үзегез яраткан ел фасылы турында инша языгыз.

**6. Исегезгә төшерегез!**

Ясалышлары буенча исемнәр **тамыр** һәм **ясалма** булалар.

| Тамыр исемнәр | Ясалма исемнәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Сүз ясагыч кушымчалы | Кушма | Парлы | Тезмә | Кыскартылма |
| аш | ашлык | ашъяулык | аш-су | каен җиләге | КФУ |

**7.** Кушма, парлы, тезмә исемнәрне табыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

1. Басуларда уңыш — ашлыклар өлгерә. 2. Урманда каен җиләге күп була. 3. Язын алмагачлар шау чәчәктә була. 4. Елга буенда иң беренче булып үги ана яфрагы чәчәк ата. 5. Көньяктан кошлар кайта.

**8.** Бирелгән сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең синоним парларын табыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| исәпсез-хисапсыз | ? | матур |
| салкын | | күп |
| шук | | суык |
| ләйсән яңгыр | | шаян |
| ямьле | | беренче язгы яңгыр |

**9.** Сыйфат дәрәҗәләрен исегезгә төшерегез. Бирелгән сыйфатларны таблицага языгыз.

| Гади дәрәҗә | Чагыштыру дәрәҗәсе | Артыклык дәрәҗәсе | Кимлек дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| матур | матуррак | иң матур | – |
| ... | ... | ... | ... |

Сыйфатлар: ап-ак, гүзәл, ямьле, иң җылы, сусыл, алсу, яхшырак, сары, алтынсу, шифалы, кып-кызыл.

**10.** 2 нче күнегүдәге тексттан сыйфатларны табыгыз, ясалышын билгеләгез.

**11.** Төрле дәрәҗәдәге сыйфатларны кулланып, җөмләләрне язып бетерегез.

1) Бу алма ..., ә бу алма ... . 2) Бу җиләк ..., ә бу җиләк ... . 3) Бу агач ..., ә бу агач ... . 4) Бүген көн ..., ә кичә ... . 5) Ык елгасы ..., ә Чулман елгасы ... . 6) Яз көне ..., ә җәй көне ... .

## 81–82 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укыгыз.

### Җиләктә

Җиләклектә
Җиләк күп.
Җиләклектә



Чиләк күп.
Һәр малайда
Бер чиләк!
Каян җыярга
Кирәк
Моның кадәрле
Җиләк?
Барыбер булмас
Тутырып,
Ашыйм гына
Утырып.

Р. Корбан

**җиләклек** — ягодник
**моның кадәрле** — столько
**барыбер** — всё равно
**булмас тутырып** — не наполнить

**2.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Җиләклектә нигә чиләк күп?
2. Уйла һәм әйт: җиләклектә ничә чиләк бар?
3. Малай нигә җиләк җыймый?

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Малай җиләк җыймый, чөнки ... .
2. Малай җиләк җыймый, шуңа күрә ... .

**4.** Диалогларны укыгыз. Иптәшегез белән сөйләшегез.

1. — Костя, әйдә урманга барабыз.
— Ә кайсы урманга?
— Күл янына. Анда бик матур урман бар.
— Еракмы?
— Юк, ерак түгел. Ярты километр.

— Мин риза. Сәгать ничәдә барабыз соң?
— Иртәнге сәгать җидедә.

2. — Лена, син бүген җиләккә барасыңмы?
— Юк, бүген бармыйм.
— Нигә?
— Бакчада эшлим: чүп утыйм, су сибәм.
— Әйдә икәү эшлибез. Эш тизрәк бетәр.
— Рәхмәт, дустым. Аннан соң урманга барырбыз.

**5.** Табышмакның җавабын табыгыз.

Башы бер, күзе унике.

**6.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: син сәгать ничәдә урманга барасың һәм ничәдә кайтасың?



**7.** Сез бу җиләк-җимешләрне яратасызмы? Алар кайда үсә?

Карлыган, балан, гөлҗимеш, кура җиләге, чия, җир җиләге, каен җиләге, миләш.

**8.** Җиләк-җимешләр нинди?

карлыган
чия
миләш
кура җиләге
балан

?

ачы
баллы
татлы
тәмле

**9.** Бергәләп көлик.



Кечкенә Валяга әнисе әбисенә булышырга куша.

Үзе кайткач сорый:

— Әбиеңә булыштыңмы?

— Булыштым. Ул суган турады. Мин еладым.

**10.** Исегезгә төшерегез!

Күрсәтү алмашлыклары: **бу** — это; **теге** — тот (та, те), **ул** — тот (та, те), **шул** — тот (та, те), **шундый** — такой.

**11.** Җөмләләрне укыгыз. Күрсәтү алмашлыкларын билгеләгез.

1) Әнә еракта урман күренә.

2) Ул урманда каен агачлары үсми, ә теге урманда каен агачлары бик күп.

3) Бу урманда гөмбә, җиләк бик күп.

4) Минем дә шул урманга барасым килә.

**12.** Поговорите с другом.

— Татарстанның табигате нинди?

— Татарстанның табигате бик бай.

— Татарстанда нинди агачлар үсә?

— Нарат, каен, имән, чыршы, юкә агачлары үсә.

— Татарстанда нинди җәнлекләр яши?

— Бүре, төлке, куян, кабан дуңгызы, поши, тиеннәр яши.

— Татарстанда нинди кошлар очрый?

— Чыпчык, ала карга, тукран, кара карга, песнәк.

— Аның климаты нинди?

— Уртача континенталь климат.

## 83–85 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемәсен табыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| мәйдан | | государство |
| төньяк | | юг |
| көньяк | | север |
| көнчыгыш | | площадь |
| көнбатыш | ? | восток |
| дәүләт | | земля |
| ил | | запад |
| җир | | ровно |
| тигез | | страна |

**2.** Бу сүзләрнең дөрес язылышын исегезгә төшерегез. Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп языгыз.

М...йд...н, д...үл...т, т...н...як, к...н...як, к...нбат...ш, к...нч...г...ш, эсс..., г...йнвар, т...б...гый, д...н...я.

**3.** 2 нче күнегүдәге сүзләр белән җөмләләр төзегез, баш һәм иярчен кисәкләрне билгеләгез.

**4.** Сүзләрнең антонимнарын языгыз.

| | | |
|---|---|---|
| җылы — ... | төньяк — ... | эссе — ... |
| зур — ... | көнчыгыш — ... | бай — ... |

**5.** Текстны укыгыз. Татарстан турында бу мәгълүматларны истә калдырып, бер-берегезгә сөйләгез.

1. Татарстан Республикасы 67,8 мең квадрат километр мәйданны алып тора. Бу — Ирландия, Литва, Шри-Ланка кебек дәүләтләрнең мәйданына тигез, дигән сүз. Республика территориясе төньяктан көньякка — 290 километрга, көнбатыштан көнчыгышка 460 километрга сузыла.

2. Татарстан Республикасы Европаның көнчыгышында — Идел белән Каманың кушылган җирендә урнашкан. Татарстан Башкортстан, Чувашия, Марий Эл, Удмуртия һәм шулай ук

Самара, Ульяновск, Киров, Оренбург өлкәләре (области) белән чикләшә (граничит).




3. Республикада уртача континенталь климат. Җәйләре җылы, кайчак бик эссе, ә кыш уртача салкын була. Иң салкын ай — гыйнвар. Гыйнварда уртача температура −14 градус. Ә иң эссе ай — июль. Июльдә уртача температура +19 градус.

4. Татарстанда иң зур табигый байлык — нефть. Шуңа күрә аны «кара алтын» диләр.

Татарстанда файдалы казылмалардан соры күмер, ташкүмер, торф, бакыр рудасы, гипс, цемент чималы, пыяла комы, известь һәм доломитлар, балчык, фосфоритлар, шифалы сулар бик күп.

**бакыр** — медь
**пыяла** — стекло
**ком** — песок
**балчык** — глина
**чимал** — сырьё

**6.** Бу фикерләр белән килешәсезме?

1. Татарстанда бик салкын климат.
2. Татарстанда иң эссе ай — август.
3. Татарстанда нефть бик аз.
4. Татарстанда файдалы казылмалар күп түгел.
5. Татарстанның территориясе зур түгел.
6. Татарстанда берничә милләт кенә яши.

**7.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп, үзара сөйләшегез.

1. — Татарстан Республикасы нинди республикалар, өлкәләр белән чикләшә?

— … .

— Татарстан Европаның кайсы ягында урнашкан?

— … .

— … ?

— Әйе, Татарстан Оренбург өлкәсе белән чикләшә.

— … ?

— Юк, Татарстан Казахстан белән чикләшми.

2. — Татарстанның мәйданы зурмы?

— … .

— … ?

— Аның мәйданы Ирландия, Литва, Шри-Ланка кебек дәүләтләрнең мәйданына тигез, дигән сүз.

— Татарстанның территориясе төньяктан көньякка ничә километрга сузылган?

— … .

**8.** Текстның 3 һәм 4 нче өлешләре эчтәлеге буенча диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

**9.** Түбәндәге фикерләр белән килешегез һәм дәвам итегез.

1. — Татарстан — бай республика.

— Әлбәттә. Татарстанда зур … .

2. — Татарстан территориясе бик зур.

— Минемчә дә шулай, чөнки ... .

3. — Татарстан файдалы казылмаларга бай.

— Син бик дөрес әйтәсең. Анда ... .

4. — Татарстан тагын да баерак республика була алыр иде.

— Мин дә шулай уйлыйм, чөнки ... .

**10.** Интернет аша «Татарстанда кошлар дөньясы», «Татарстанда хайваннар дөньясы» темаларына материал туплагыз. Сөйләргә өйрәнегез.

**11.** Әйтик, сез халыкара фестивальдә катнашасыз. Туган ягыгыз турында нәрсәләр сөйләр идегез? Төркемнәрдә сөйләргә өйрәнегез.

**12.** Диалогны үзара сөйләшергә өйрәнегез.

— Коля, синең нинди илләрдә булганың бар?

— Төркиядә ял иттек.

— Төркиянең табигате матурмы?

— Безнең табигать матуррак. Бездәге урманнар, кырлар, елгалар Төркиядә юк.

— Әйе, бездә Төркиядәге кебек диңгез булса, без тагы да бәхетлерәк булыр идек. Син ничек уйлыйсың?

— Мин дә шулай уйлыйм. Ә кыш көне бездә ничек матур!

— Шулай шул, ап-ак карлы кышта чана, чаңгы, тимераякта шуу бик рәхәт.

— Әйе, без паркта көн дә чаңгы, тимераякта шуабыз, ә җәй көне волейбол уйнарга яратабыз.

— Безнең янда гына урман бар. Без үзебез футбол мәйданчыгы ясадык. Командалар ярышы оештырабыз.

# БАШКАЛАБЫЗ КАЗАН

## 86–88 нче дәресләр



**1.** Текстны укыгыз. Башкалабыз Казан турында сөйләргә әзерләнегез.

Башкалабыз Казан — бай тарихлы зур, матур шәһәр. Бөек шагыйрь Габдулла Тукай, Казанны яратып: «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» — дип язган. Казан үзенең искиткеч күп тарихи урыннары, музейлары, фән үзәкләре, югары уку йортлары, театрлары, спорт корылмалары белән дөньякүләм данлыклы шәһәр санала. Бүген Казан шәһәренең халкы 1 млн 200 мең кешедән артык. Казанның визит карточкасы — Меңьеллык мәйданы. Ул Россиядә иң зур мәйданнарның берсе. Аның территориясе 100 000 квадрат метр. Анда Үзәк стадион урнашкан. Мәйдан 2000 нче елда төзелә, ә 2005 нче елдан аны Казанның меңьеллыгы уңаеннан Меңьеллык мәйданы дип атый башлыйлар. Мәйдан Казан Кремленә килеп тоташа. Шәһәрнең күп бәйрәмнәре, шул исәптән Җиңү көне дә шунда үткәрелә.



Казанны Миллениум күпере бизи. Аның озынлыгы 831 метр,

килү юллары белән 1524 метр. Күпер 6 юл полосасыннан тора, җәяүлеләр өчен тротуар да бар. Күперне «М» хәрефе формасындагы пилон бизи.



Казанга килгән кунаклар һәм студентлар шәһәр үзәгендәге Бауман һәм Петербург урамнарын аеруча ярата. Петербург урамының бизәлеше Санкт-Петербург шәһәре архитектурасына охшатып эшләнгән.



Бауман урамы кешеләр өчен ял итү, очрашу һәм сәүдә үзәге булып тора.

Казан — музейлар шәһәре. Мәсәлән, Габдулла Тукай, Шәриф Камал, Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев музейлары бар. Бу музейларда күренекле кешеләрнең тормыш юлы чагыла, шәхси көнкүреш әйберләре, кулъязмалары саклана.

**2.** Тексттагы җөмләләрне кулланып, текстка план төзегез.

**3.** План пунктларына туры китереп, башкалабыз Казан турында диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

**4.** Казанда метро төзелү тарихын Интернеттан табып укыгыз.

**5.** Түбәндәге план буенча Казан метрополитены турында чыгышка әзерләнегез.

1. Метроның төзелә башлавы.
2. Метро ачылу.
3. Метро станцияләре.
4. Метро төзелеше дәвам итү.

**6.** Җөмләләрне укыгыз. Исемнәрнең тартымын, килешләрен билгеләгез.

Казанны биш диңгез порты дип йөртәләр. Казан портыннан Каспий диңгезенә, Балтыйк диңгезенә, Кара диңгезгә, Ак диңгезгә чыгып була.

## 89–90 нчы дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе турында сөйләргә әзерләнегез.



1865 нче елның 24 нче гыйнварында тантаналы төстә Казанда беренче китапханә ачыла. Сирәк китаплар җыючы Иван Второвның улы Николай Второв бу китапханәгә әтисенең 2 меңгә якын китабын бүләк итә. Иван Второв рус һәм дөнья классикларының әсәрләрен, тарих һәм география буенча хезмәтләр туплаган була. Алар китапханәдә бүген дә кыйммәтле хәзинә санала (булып тора).

**тантаналы төстә** — торжественно
**сирәк** — редкое
**тупланган** — накоплено
**хәзинә** — клад

Китапханә тарихын өйрән

**2.** Түбәндәге сорауларга җавап бирегез. Сораулар буенча текстның эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

1. Милли китапханә кайчан ачыла?
2. Китапханәгә кем нигез сала?
3. Николай Второв бу китапханәгә нәрсә бүләк итә?

**3.** Интернеттан Милли китапханә сайтын табыгыз. Китапханә турында белешмә туплагыз, сөйләргә өйрәнегез.

**4.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез.

1. — Син китапханәгә барасыңмы?
— Әйе, мин китапханәгә барам.
— Сиңа нинди китап кирәк?
— Миңа Муса Җәлил турында китап кирәк.

2. — Әйдә китапханәгә барабыз.
— Бүген китапханә эшлиме?
— Әйе, бүген китапханә эшли.
— Китапханә сәгать ничәдә ачыла?
— Китапханә сәгать унда ачыла.

3. — Керергә мөмкинме?
— Рәхим итегез.
— Китапханәгә язылырга мөмкинме?
— Әлбәттә, мөмкин. Фамилияң, исемең ничек?
— Романов Олег.
— Ничәнче сыйныфта укыйсың?
— 7 нче сыйныфта.
— Адресың ничек?
— Шамил Усманов урамы, 6 нчы йорт, 15 нче квартира.
— Нинди китап кирәк?
— Габдулла Тукайның шигырьләр китабы кирәк.

**5.** Диалогны укыгыз, үзара сөйләшегез.



— Альбина, әйдә китапханәгә барыйк әле.
— Нигә?
— Миңа Александр Сергеевич Пушкинның әсәрләре кирәк.
— Миндә аның әсәрләре бар.
— Нинди әсәрләре бар?
— «Борис Годунов», «Капитан кызы», «Евгений Онегин», «Руслан һәм Людмила».
— Миңа «Капитан кызы» кирәк.

**6.** Кызыклы фактларны дусларыгызга сөйләгез.




Беренче китаплар 5 мең еллар элек борынгы Мисырда барлыкка килгән. Китапларны папируска язганнар.

Россиядә беренче русча уку китабын — букварьны Иван Фёдоров исемле китап бастыручы 1564 нче елда чыгара.

Россиядә беренче татар басма китабы 1722 нче елда Әстерхан шәһәрендә чыга. Ул гарәп хәрефләре белән язылган була.



**7.** Ә сез беләсезме?

Беренче Казан ирләр гимназиясе 1758 нче елда ачыла. Анда атаклы шәхесләр белем ала. Алар кемнәр?






Б е л е ш м ә   ө ч е н   ( д л я   с п р а в к и ): И.И. Шишкин, Н.И. Лобачевский, С.Т. Аксаков, А.М. Бутлеров.

# 91–93 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Казанда нинди театрлар бар? Аларның исемнәрен әйтергә өйрәнегез.

## Казан — театрлар шәһәре

Казанда җиде профессиональ театр эшли: Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Василий Качалов исемендәге Казан рус дәүләт зур драма академия театры, Казан дәүләт яшь тамашачы театры, Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры, «Әкият» Татар дәүләт курчак театры. Театрларга шәһәр халкы гына түгел, башка төбәкләрдән дә тамашачылар бик теләп килә.



Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры



Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры



«Әкият» Татар дәүләт курчак театры



Василий Качалов исемендәге Казан рус дәүләт зур драма академия театры



Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры



Казан дәүләт яшь тамашачы театры

**2.** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасы турында укыгыз. Диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасы Һади Такташ урамында, Кабан күле буенда урнашкан. Искиткеч матур театр бинасын ачу тантанасы 2025 нче елда узды.



Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры

Бинаның 1500 тамашачыны сыйдырышлы 4 залы бар. Һәр зал — үзе бер сәнгать әсәре.

Фойега аяк басуга, аның искиткеч бизәлешенә, милли орнаментларга игътибар итәсең. Махсус яктырткычлар әлеге рәсемнәрнең тәэсир итү көчен тагын да баета.

Көнчыгыш зал 242 урынга исәпләнгән.

Универсаль залда 300 ләп кеше утыра ала. Төп зал — 766 тамашачыга, камера залы 60 кешегә исәпләнгән.

**3.** Диалогларны рольләргә бүлеп укыгыз.

1. — Әйдә иртәгә театрга барабыз.
— Кайсы театрга?
— Опера һәм балет театрына.

2. — Безгә иртәгә театр килә.
— Нинди театр?
— Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры.
— Ә нинди спектакль куялар?
— «Авыл эте Акбай» спектаклен.

**4.** Диалогларга кирәкле репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

1. — ... ?
— Әйе, без каникулда Казанга бардык.
— Ә театрларга бардыгызмы?
— Татар дәүләт Академия театрына бардык.
— Нинди спектакль карадыгыз?
— ... .

2. — … ?
— Спектакль кичке сәгать 7дә башлана.
— … .
— Әйе, билетлар бар.
— … ?
— Алдагы рәтләргә билетлар юк инде.

3. — Надя, мин театрга барам. Әйдә бергә барабыз.
— Ә билетлар бармы?
— … .
— Ничә сум тора?
— … .

**5.** Таблицаны тутырыгыз.

| Язучылар, шагыйрьләр | Композиторлар | Җырчылар | Рәссамнар |
| --- | --- | --- | --- |
| … | … | … | … |

Муса Җәлил, Габдулла Тукай, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Илһам Шакиров, Бакый Урманче, Харис Якупов, Әлфия Афзалова, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Лотфулла Фәттахов, Мәхмүт Газизов, Роберт Миңнуллин, Венера Ганиева, Зәйнәп Фәрхетдинова, Салават Фәтхетдинов, Луиза Батыр-Болгари, Гүзәл Уразова, Раяз Фасыйхов, Ришат Төхвәтуллин, Филүс Каһиров, Нәҗип Җиһанов, Хәсән Туфан, Илдар Юзеев, Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Илдар Зарипов, Сара Садыйкова.

**6.** Үзегез яшәгән төбәктәге композиторларның, язучыларның, шагыйрьләрнең, рәссамнарның, җырчыларның исемнәрен атагыз. Алар турында сөйләргә әзерләнегез.

## 94–95 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Танылган рәссам Бакый Урманче турында сөйләргә әзерләнегез.


Бакый Урманче. Автопортрет

Бакый Урманче — Татарстанның халык рәссамы, сынчы, график һәм архитектор. 2027 нче елда Татарстан Республикасы аның тууына 130 ел тулуны билгеләп үтә. Ул үзенең иҗатында татар халкының мәдәни кыйммәтләрен, йолаларын саклый, үстерә. Ул татар милли сынлы сәнгатенә нигез сала.

Бакый Урманче Буа районы Күл Черкене авылында туа. Күл Черкене авылында рәссамның музей-йорты бар. Анда аның рәсемнәре, картиналары, татар милли киеме эскизлары, «Шүрәле», «Кисекбаш» поэмаларына эшләнгән графика серияләре, сыннары саклана. Музейда рәссамның шәхси әйберләре дә бар: 1951 нче елгы эскизлар дәфтәре, кружкасы, карандашлары, каләмнәре.

Бакый Урманченың иҗаты белән Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда танышырга була. Биредә аның әсәрләренең бай тупланмасы саклана.

**халык рәссамы** — народный художник
**сынчы** — скульптор
**сынлы сәнгать** — изобразительное искусство
**мәдәни кыйммәтләр** — культурные ценности
**йолалар** — традиции

Бакый Урманче. «Урал тау итәгендә»

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Бакый Урманче Татарстанның ... . 2. Ул үзенең иҗатында ... . 3. Буа районы Күл Черкене авылында ... . 4. Ул татар милли ... . 5. Музейда аның рәсемнәре, картиналары, ... . 6. Музейда рәссамның ... . 7. Бакый Урманченың иҗаты белән ... .



**3.** Текстны укыгыз. Рәсемгә карап, аны дәвам итегез.

Бакый Урманче үзенең иҗатында күп мәртәбә Габдулла Тукай иҗатына мөрәҗәгать итә. Шагыйрьнең Яңа Кырлайдагы әдәби-мемориаль комплексында Бакый Урманче хезмәтләре бик күп. Ул ... .

## 96–98 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укырга һәм транскрипция билгеләре белән язарга өйрәнегез, тәрҗемәсен сүзлектән табыгыз.

Мактаулы, тормыш, борчыла, ышанычлы, сәнгать, әдәбият, рухи, таләпчән, иҗат, сердәш, мирас.

**2.** Тәрҗемәне дәвам итегез. Уйлагыз, нинди кушымча яңа сүз ясый?

| | |
|---|---|
| авыл — деревня (село) | авылдаш — односельчанин |
| юл | юлдаш |
| фикер | фикердәш |
| сер | сердәш |
| шәһәр | шәһәрдәш |
| әңгәмә | әңгәмәдәш |

**3.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

**Татарстан Республикасының халык артисты**

1. Заслуженный артист Республики Татарстан.
2. Заслуженный деятель искусств.
3. Народный артист Республики Татарстан.

**4.** Композитор Сара Садыйкова турында укыгыз.

Сара Садыйкова 1906 нчы елда Казан шәһәрендә туа. Аның әнисе гармунда уйнаган, Сараның да күңеле музыкага



тартыла. Сара Мәскәү консерваториясен уңышлы тәмамлый.

Сара Садыйкова — Татарстанның халык артисты. Ул өч йөздән артык җыр, ике комедиягә музыка, романслар, вальслар иҗат иткән. Аның җырларын профессиональ артистлар да, халык та бик яратып җырлый.

Сара Садыйкова мәңгегә халык күңелендә. Яр Чаллы шәһәренең иң зур концертлар залы Сара Садыйкова исемен йөртә.

Ул танылган композитор гына түгел, бик күпләрнең якын дусты, яшь шагыйрьләрнең һәм җырчыларның тәҗрибәле остазы, ярдәмчесе иде.

**5.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибе буенча урнаштырыгыз.

Сара Садыйкова өч йөздән артык җыр, ике комедиягә музыка, романслар, вальслар иҗат итә. Сара Садыйкова 1906 нчы елда Казан шәһәрендә туа. Ул танылган композитор гына түгел, бик күпләрнең якын дусты, яшь шагыйрьләрнең һәм җырчыларның тәҗрибәле остазы, ярдәмчесе иде.

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Сара Садыйкова — уникаль шәхес, чөнки ... .
2. Сара Садыйкова композитор гына түгел, ә ... .
3. Сара Садыйкованың җырларын ... .
4. Мәскәү консерваториясен тәмамлагач, ... .

**7.** Сорауларга җавап бирегез, үзара сөйләшегез.

1. Сара Садыйкова ничәнче елда һәм кайда туа?
2. Сара Садыйкованың музыкаль сәләте кемнән килә?
3. Сара Садыйкова нинди музыкаль әсәрләр яза?
4. Композитор опералар язганмы?
5. Сезгә Сара Садыйкованың нинди кешелек сыйфатлары ошый?

Сара Садыйкова тавышын тыңла

**8.** Җөмләләргә сораулар куегыз.

1. Сара Садыйкова көйләре тыңлаучының күңелен күтәрә.
2. Сара Садыйкова яшь шагыйрьләрнең, җырчыларның тәҗрибәле остазы иде.
3. Сара Садыйкованың җырларын Казахстанда, Уралда һәм башка җирләрдә яратып җырлыйлар.
4. Ул — Татарстанның халык артисты.
5. Сара Садыйкова романслар, вальслар иҗат иткән.
6. Яр Чаллыда зур концертлар залы Сара Садыйкова исемен йөртә.

**9.** Гөлшат Зәйнашева шигыренә Сара Садыйкова җыр иҗат иткән. Илебезнең матурлыгы җырда ничек сурәтләнә?

### Үз илемдә

Яз да сайрый, көз дә сайрый
Бер нәни кош бакчамда,
Шул кошчыкны сагынып кайтам,
Кая гына барсам да.
Бакчам гади, үсми анда
Кипарислар, хөрмәләр.
Миңа таллар кипаристан
Матуррак күренәләр,
Исем китми читтә үскән
Әфлисунга, бананга.
Ачы булса да гашыйк мин
Миләш белән баланга.
Мин гашыйк илемдә үскән
Талларның барчасына.
Үз илемдә ямьле миңа
Бәрәңге бакчасы да.

**10.** Шигырьдән туган илгә мәхәббәт сурәтләнгән юлларны табып, кабат укыгыз.

**11.** Бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә сөйләшегез.

Халыкның бер йорты бар, ул да булса — туган ил.
Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.

## 99–102 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемәне дәвам итегез. Җөмләләр төзегез.

барыр идем — пошёл бы
сөйләр идең — ...
күрсәтер иде — ...
әйтер идек — ...
эшләр идегез — ...
яшәр иделәр — ...

**2.** Җөмләләрне үрнәк буенча тәрҗемә итегез.

Үрнәк: Яхшы ял итәр өчен, тырышып эшләргә кирәк. — Чтобы хорошо отдохнуть, надо хорошо поработать.

1. Туган җирне бай итәр өчен, тырышып эшләргә кирәк.
2. Белемле кеше булыр өчен, күп укырга кирәк.
3. Табигатьне саклар өчен, аның турында һәрвакыт кайгыртырга кирәк.

**3.** Тәрҗемә итегез.

1. Мне хочется написать статью о Татарстане. 2. Чтобы жить хорошо, надо много работать. 3. Нам не хочется уезжать из республики. 4. Чтобы приносить пользу стране, надо её любить.

**4.** Казан шәһәреннән Сөмбел «Ялкын» журналына менә нинди мәкалә җибәргән. Сез аның фикерләре белән килешәсезме?

Кешегә һәрвакыт яхшыдан яхшы кирәк. Без булмаган җирдә һәрвакыт рәхәтрәк кебек тоела. Шуңадыр, күрәсең, күпләрнең чит илгә барасы килә. Их, бөтен кеше мактаган җирне бер барып күрсәң иде! Чит илне ничегрәк күз

алдына китерәбез соң без? Затлы, бай, мул тормыш... Нәкъ шулай тоела менә: төрле төстәге якты утлар, машиналар, гамбургерлар, кырыс полицейскийлар... Кыскасы, беләбез инде, беләбез.



Әгәр дә чит илдә дустым булса, мин аңа безнең Татарстан турында сөйләр идем. Безнең тормыш, ничек яшәвебез күпләргә билгеле түгел шул. Туган ягыбызны, ягъни Татарстаныбызны әкият иле итәсе килә безнең. Аның өчен бөтен шартлар да җитәрлек. Габдулла Тукай әкиятләренең геройлары «яшәгән» калын урманнар да, уңдырышлы туфрагыбыз да, «алтын балыклар» йөзгән мул сулы елгалар да, җир асты торбалары буйлап аккан нефть тә бар бездә. Татарстанны бай, цивилизацияле төбәк итәр өчен, үз җирен, туган ягын чын күңелдән яраткан кешеләр кирәк. Республикабыз гөрләп чәчәк атсын өчен, тырышып эшләүче кешеләр кирәк. Алар батыр, акыллы, намуслы булсыннар.



Яшь буын, минем буын, дусларым, яшьтәшләрем үсеп килә. Татарстанның киләчәге — безнең кулларда.

**икътисади** — экономический
**ичмаса** — хотя бы
**мөнәсәбәт** — отношение
**кырыс** — строгий
**уңдырышлы туфрак** — плодородная почва
**мул** — богатый, изобильный
**чын күңелдән** — от всей души
**гөрләп чәчәк атсын өчен** — чтобы процветала

**5.** Җөмләләрнең эчтәлеге текстка туры киләме?

1. Без булмаган җирдә һәрвакыт рәхәтрәк кебек тоела. 2. Туган илебезнең табигате бик бай. 3. Татарстан территориясендә мул сулы елгалар күп түгел. 4. Татарстан аркылы Идел, Кама, Агыйдел, Вятка (Нократ) кебек зур елгалар ага. 5. Туган илебезне, ягъни үз Татарстаныбызны тагын да матуррак, баерак итәсе килә безнең. 6. Татарстанны бай ил итәр өчен, үз илен чын күңелдән яраткан кешеләр кирәк.

**6.** Сүзтезмәләрдә кайсы ил турында сүз бара?

1. Калын урманнар, мул сулы елгалар, уңдырышлы туфрак, зур нефть ятмалары (залежи).

2. Төрле төстәге утлар, машиналар, кырыс полицейскийлар, затлы, бай, мул тормыш.

**7.** Җөмләләрдән аергычларны табыгыз, аларга сораулар куегыз.

Габдулла Тукай әкиятләренең геройлары «яшәгән» калын урманнар да, уңдырышлы туфрагыбыз да, «алтын балыклар» йөзгән мул сулы елгалар да, җир асты торбалары буйлап аккан нефть тә бар бездә.

**8.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Минем чит илдә дустым булса, ... .
2. Татарстанны цивилизацияле төбәк итәр өчен, ... .
3. Республикабыз гөрләп чәчәк атсын өчен, ... .
4. Татарстанны әкият иле итәр өчен, ... .

**9.** Бу җөмләләрнең эчтәлеген ничек аңлыйсыз? Төркемнәрдә фикерләшегез, сөйләшергә әзерләнегез.

1. Без булмаган җирдә һәрвакыт рәхәтрәк кебек тоела.
2. Республикабыз гөрләп чәчәк атсын өчен, тырышып эшләүче кешеләр кирәк.
3. Ул кешеләр батыр, акыллы, намуслы булсыннар.
4. Яшь буын, минем буын, дусларым, яшьтәшләрем үсеп килә.
5. Татарстанның киләчәге — безнең кулларда.

**10.** Телевизордан «Хәбәрләр» («Вести») тапшыруын карагыз. Татарстан Республикасы турында нинди яңалыклар, хәбәрләр ишеттегез? Сөйләргә әзерләнеп килегез.



# Сүзлек

## А

**авылдаш** — односельчанин
**агуланырга** — отравиться, травиться
**агулы** — ядовитый
**агыз** — пролей
**аергыч** — определение
**аеруча** — особенно
**аерылып тора** — выделяется
**аерым** — отдельно; отдельный
**аккош** — лебедь
**аксыл** — беловатый, белёсый
**аксыл көрән** — бежевый
**алайса** — если так, тогда
**алан** — поляна
**алдакчы** — обманщик, врун
**алдаша** — обманывает, врёт
**алмашлык** — местоимение
**аннан соң** — после этого
**аныклагыч** — поясняющее, уточняющее слово
**аныклык** — ясность, конкретность
**аптыраш** — растерянность
**аралашу** — общение
**аркылы** — через, поперёк
**арт** — зад
**артка** — назад
**артык** — слишком, более
**аръяк** — та сторона, заречье
**ары** — дальше, больше
**арый** — устаёт
**арыш** — рожь
**ас** — низ
**ат** — бросай, стреляй
**атау җөмлә** — назывное предложение
**атказанган** — заслуженный
**атла** — шагай
**ауна** — валяйся
**ачулы** — злой
**ачы** — горько, горький; кисло, кислый
**ачыш** — открытие
**ашык** — торопись

## Ә

**әгәр** — если
**әдәбият** — литература
**әдәпле** — вежливо; вежливый
**әдип** — писатель, литератор
**әзер** — готовый
**әйтем** — поговорка
**әллә** — или, либо
**әңгәмәдәш** — собеседник
**әсәр** — произведение
**әшәке** — плохой; грязный

## Б

**балан** — калина
**барыбер** — всё равно
**барысы** — все, всего
**басым** — ударение
**башваткыч** — головоломка
**башка** — другой
**башкача** — по-другому
**башлангыч** — начальный
**башта** — сначала, сперва
**бәйлек** — послелог
**бәйлек сүз** — послеложное слово
**бәла** — беда, несчастье
**бәлки** — возможно, вероятно
**бәргәләнә** — мечется
**бәс** — иней, изморозь
**бәялә** — оцени
**бераз** — немного
**бервакыт** — однажды

**бергә, бергәләп** — вместе
**бердәнбер** — единственный
**беркем** — никто
**бернинди** — никакой
**берничә** — несколько
**берьюлы** — сразу, одновременно
**билгеләү** — отметь
**болга** — маши
**боргалана-сыргалана** — крутится-вертится, извивается
**борыл** — повернись
**ботак** — ветка, сук
**борчыла** — беспокоится, тревожится
**бөек** — великий
**Бөек Ватан сугышы** — Великая Отечественная война
**бөҗәк** — насекомое
**бөртек** — крупинка, зерно; капля
**бөтен** — целый, весь
**бөтенләй** — полностью
**бугай** — кажется, как будто
**буенча** — вдоль, по
**буйлап, буенча** — по
**бурыч** — долг
**бута** — путай, мешай
**буталчык** — запутанный
**буш** — пусто; пустой
**буын** — поколение
**бүлдермә** — не перебивай
**бүлек** — глава
**бүрәнә** — бревно
**бүтән** — другой

# В

**вакыйга** — событие, происшествие
**ват** — разбей, сломай, расколи
**ватык** — разбитый, сломанный
**вәгъдә** — обещание, обет
**вөҗдан** — совесть

# Г

**гадәт** — привычка, навык
**гадел** — честно, честный; справедливо, справедливый
**гаеп** — вина
**гаепле** — виновный
**гаҗәпләнү** — удивляйся
**газап** — мучение
**галим** — учёный
**гасыр** — век
**гафу ит** — извини, прости
**гашыйк** — влюблённый, любящий
**гәүдә** — туловище, тело
**гомер** — жизнь
**гореф-гадәт** — обычай, традиция
**горурлан** — гордись
**гөлҗимеш** — шиповник
**гөрләвек** — ручей

# Д

**данлыклы** — знаменитый, прославленный
**дәва** — лекарство
**дәлилләү** — докажи; аргументируй
**дәрәҗә** — степень, звание
**дәрт** — страсть
**дәһшәтле** — страшный, зловещий
**дерелди** — дрожит
**димәк** — следовательно, таким образом, значит
**дусларча** — по-дружески
**дым** — влага

# Е

**егет** — парень
**елан** — змея
**елмай** — улыбайся
**ерта** — рвёт
**еш** — часто

## Ж

**жай** — удобный момент, возможность
**җәза** — наказание
**җәмгыять** — общество
**җәяүле** — пеший, пешеход
**җимерелә** — разваливается
**җиңелчә** — слегка, налегке
**җитәкче** — руководитель
**җитәрлек** — достаточный
**җитди** — серьёзно; серьёзный
**җитез** — ловко, ловкий; шустро, шустрый
**җитеш** — успевай
**җуйма** — не теряй
**җыентык** — сборник

## З

**зарарлый** — вредит
**зарлан** — жалуйся
**затлы** — знатный, благородный
**зыянлы** — вредно; вредный

## И

**игълан** — объявление
**игътибарлы** — внимательный
**иҗат** — творчество
**иҗек** — слог
**икътисади** — экономический
**илт** — отнеси
**имеш** — будто бы, мол, дескать
**инеш** — речка; родник
**иптәш** — товарищ
**иректе** — свободный
**иреш** — добейся, достигни
**иркәлә** — ласкай
**иркен** — просторно; просторный
**исән** — живой, здоровый
**исәнлек** — здоровье
**исемлек** — список
**иске** — старый
**искиткеч** — изумительно; изумительный
**исни** — нюхает
**истә калдыр** — запомни
**ичмаса** — хотя бы
**ишек төбе** — место перед дверью
**ишет** — услышь
**ия** — подлежащее

## Й

**йодрык** — кулак
**йомшак** — мягко; мягкий
**йонлач** — мохнатый, волосатый
**йөз** — плыви
**йөткер** — кашляй

## К

**кабан** — кабан
**кабер** — могила
**кабырга** — ребро
**казылма** — ископаемое
**кайбер** — некоторый
**кайвакыт** — иногда
**кайгырт** — заботься
**кайнаган** — кипячёный
**кайсы** — который
**кайчак** — иногда
**кал** — останься
**калтыра** — трясись
**калын** — густой
**камыр** — тесто
**кан** — кровь
**канәгать** — довольный
**карчыга** — ястреб
**каршы** — противоположный, напротив
**каурый** — перо
**кәеф** — настроение

**кемдер** — кто-то
**кереш сүз** — вводное слово
**кешелек** — человечество
**кигез** — одень
**киләсе, киләчәк** — будущий
**килен** — невестка, сноха
**килеш** — падеж
**килешү** — договор, сговор
**кимерә** — грызёт
**кими** — уменьшается, убавляется
**кимчелек** — недостаток
**кинәт** — внезапно, вдруг
**киңәш ит** — посоветуй
**киресенчә** — наоборот
**кис** — режь
**кисәкчә** — частица
**кит аннан** — уходи оттуда; не может быть
**кичереш** — переживание
**коелып төште** — рассыпался; растерялся
**кондыз** — бобр
**корсак** — живот
**коточкыч** — страшный
**кочаклый** — обнимает
**көй** — мелодия, мотив
**көймә** — лодка
**көл** — зола
**көнбатыш** — запад
**көндезге** — дневной
**көнкүреш** — быт
**көнчыгыш** — восток
**көньяк** — юг
**көрәш** — борьба
**көрәшче** — борец
**көчәй** — усиливайся
**куак** — куст
**куан** — радуйся
**куе** — густо; густой
**куллан** — используй
**кулъязма** — рукопись
**куркусыз** — бесстрашный
**куркыныч** — страшно; страшный
**куркыта** — пугает
**кушамат** — кличка, прозвище
**күнекмәгән** — непривычный
**күңел ач** — развлекайся
**күптән** — давно
**күпчелек** — большинство
**күргәзмә** — выставка
**күрешергә** — здороваться, встречаться
**күч** — пересядь, перейди
**күчер** — спиши
**кызган** — пожалей
**кызганычка каршы** — к сожалению
**кызыксын** — интересуйся
**кыйммәтле** — дорогой, дорогостоящий
**кыйна** — бей
**кылана** — кокетничает, изображает
**кыланыш** — поступок, выходка
**кырыс** — суровый, строгий, резкий
**кыстыр** — прищеми, вложи
**кычыткан** — крапива
**кыю** — смело, смелый; отважно, отважный
**кыяфәт** — внешний вид

# Л

**лаек була** — удостоен
**ләлә** — тюльпан
**лачын** — сокол

# М

**мажаралы** — приключенческий
**максат** — цель
**мактанчык** — хвастун
**мактаулы** — похвальный
**матдә** — вещество, материя
**мәгълүмат** — информация

**мәгънә** — смысл
**мәдәни** — культурный
**мәдәният** — культура
**мәҗбүри** — обязательный
**мәкалә** — статья
**мәкаль** — пословица
**мәңге** — вечно; вечный
**мәртәбә** — раз
**мәрхәмәтле** — милосердный
**мендәр** — подушка
**мескен** — несчастный, жалкий
**микән** — ли, то ли
**мирас** — наследие
**могҗиза** — чудо
**моны** — это
**моңлы** — мелодично; мелодичный
**мөгаен** — наверное
**мөмкин** — можно
**мөнәсәбәт** — отношение
**мөстәкыйль** — самостоятельно; самостоятельный
**мөһим** — важно; важный
**муенса** — бусы, ожерелье
**мул** — щедро, щедрый; изобильный
**мүк** — мох

# Н

**надан** — необразованный; неуч, невежа
**намус** — честь
**начар** — плохо; плохой
**нәкъ** — именно, точь-в-точь
**нәшрият** — издательство
**нигез** — основа
**ниһаять** — наконец
**Нократ** — Вятка
**нур сип** — излучай
**ныгыт** — крепи, укрепи

# О

**озат** — проводи
**озын** — длинно; длинный
**оныт** — забудь
**онытылмаслык** — незабываемый
**орлык** — семя
**остаз** — наставник
**охшаш** — похожий
**оч** — конец, кончик
**очраш** — встреться
**очсыз** — дёшево; дешёвый
**ошый** — нравится
**оял** — стыдись
**оялчан** — застенчиво, застенчивый; робко, робкий; совестливо, совестливый
**оят** — стыд

# Ө

**өз** — рви
**өзгәлән** — разрывайся
**өзек** — отрывок
**өй** — складывай
**өлешчә** — частично
**өлкә** — область
**өлкән** — взрослый, старший
**өмет** — надежда
**өр-яңа** — совершенно новый
**өстәмә** — дополнительный

# П

**пәрәмәч** — перемяч
**песнәк** — синица
**пешер** — вари, пеки
**почмак** — угол
**поши** — лось
**пөхтә** — опрятно; опрятный

# Р

**расла** — подтверди, докажи
**рәнҗет** — обижай
**рәсем** — рисунок
**рәссам** — художник
**рәхәт** — приятно, хорошо
**рәхим ит** — добро пожаловать
**риза** — согласен
**ризык** — пища
**рөхсәт** — разрешение
**рух** — дух, душа
**рухи** — духовно; духовный

# С

**сабыр** — терпеливо; терпеливый
**сагын** — скучай
**сагыш** — тоска
**саен** — каждый
**сайла** — выбирай
**сайланма** — избранный
**сакла** — береги
**сына** — ломается
**саңгырау** — глухой
**саран** — скупо; скупой
**саулык** — здоровье
**саф күңелле** — чистосердечный, искренний
**сәбәп** — причина
**сәлам** — привет
**сәламәт** — здоровый
**сәләт** — способность
**сәдәп** — пуговица
**сәхнә** — сцена
**сәяхәт** — путешествие
**себерке** — метла, веник
**сердәш** — закадычный друг
**сиз** — чувствуй
**сизгер** — чуткий
**симез** — тучный, полный, жирный
**сирәк** — редко; редкий
**соклан** — восхищайся
**соклангыч** — восхитительно, восхитительный; изумительно, изумительный
**соңга кал** — опоздай
**сөекле** — любимый
**сөен** — радуйся
**сөенеч** — радость
**сөйкемле** — симпатичный, обаятельный
**сөйлә** — рассказывай
**сөю** — любовь
**сөяк** — кость
**сугышчан** — боевой
**сугышчы** — воин, боец
**суела** — сдирается
**суз** — тяни
**сукыр** — слепой
**сул** — левый
**сурәтлә** — изображай
**сусыл** — сочный, водянистый
**сүзеңдә тор** — держи слово
**сүндер** — туши, выключи
**сыек** — жидко; жидкий
**сызгыр** — свисти
**сыйфат** — прилагательное
**сыйфат фигыль** — причастие

# Т

**таба** — сковорода
**табиб** — врач
**табигать** — природа
**табигый** — природный, естественный
**табыш** — находка
**табышмак** — загадка
**тагын** — ещё
**тал** — ива
**тамаша** — представление
**тамашачы** — зритель
**тамчы** — капля

**тамыр** — корень
**тантаналы** — торжественно; торжественный
**танылган** — известный
**таныш** — знакомый
**таң калдыр** — удиви
**тапкыр** — раз
**тапшыр** — передай
**тапшыру** — передача
**тар** — узкий
**таратучы** — распространитель
**тарих** — история
**тартык** — согласный
**тартыл** — потянись
**тасма** — лента
**татлы** — сладко; сладкий
**тату** — дружно; дружный
**ташлан** — бросайся
**таяк** — палка
**тәбәнәк** — низко; низкий
**тәвәккәл** — решительный
**тәҗрибә** — опыт
**тәкъдим ит** — предложи
**тәмамлык** — дополнение
**тәмәке тарту** — курение
**тән** — тело
**тәэсир** — влияние
**тезүче** — сочинительный
**тегермән** — мельница
**теләгәнчә** — вволю, сколько угодно
**теләк** — желание
**телем** — кусок
**текә** — крутой
**теркәгеч** — союз
**терлек** — скот
**тешлә** — кусай
**тигез** — ровно; ровный
**тиздән** — скоро
**тик яту** — бездельничать
**тимәскә** — не трогать
**тимер юл** — железная дорога
**тиңдәш кисәкләр** — однородные члены
**тип** — пинай
**тирлә** — потей
**токым** — порода
**торна** — журавль
**төбәк** — регион
**төгәл** — точно; точный
**төзә** — целься
**төзүче** — строитель
**төлке** — лиса
**төн** — ночь
**төнбоек** — кувшинка, водяная лилия
**төп** — основа
**төпчек** — младший ребёнок
**төрен** — кутайся
**төркем** — группа
**төтен** — дым
**төчкер** — чихай
**тугрылыклы** — верный
**тузганак** — одуванчик
**тукта** — остановись
**тукталыш** — остановка
**туктат** — останови
**тупас** — грубо, грубый; невежливо, невежливый
**туры килә** — подходит
**туфрак** — почва
**түбәтәй** — тюбетейка
**түгәрәк** — круглый
**түлә** — плати
**түрдән уз** — проходи
**тыйнак** — скромный
**тынычлык** — мир, спокойствие

# У

**уз** — проходи
**уң** — правый
**уңган** — умелый; трудолюбивый
**уңдырышлы** — плодородный
**урнаш** — устройся, устраивайся
**уртак** — общий, совместный

**уртаклык** — общность, взаимность
**усак** — осина
**уч** — ладонь
**учак** — костёр
**уян** — проснись
**уят** — разбуди

## Ү

**үз** — свой
**үзара** — взаимный
**үзгәрт** — измени
**үзе** — сам, само, сама
**үзенеке** — свой
**үзенчәлекле** — своеобразный
**үзләренчә** — по-своему, как сами желают
**үзлегеннән** — произвольно; самостоятельно
**үкен** — раскаивайся
**үкенеч** — раскаивание
**үкенечле** — жалко; досадно
**үлем** — смерть
**үпкәлә** — обижайся
**үрмәлә** — ползай
**үрчет** — разводи
**үсемлек** — растение
**үтерә торган** — смертельный
**үткәр** — пропусти
**үткен** — остро, острый; остроумный

## Ф

**файда** — польза, выгода
**файдалан** — пользуйся, используй
**файдалы казылмалар** — полезные ископаемые
**фәрман** — приказ, повеление, указ
**фикер** — мысль

## Х

**хаклы** — прав; законный, справедливый
**хәбәр I** — весть, известие
**хәбәр II** — сказуемое
**хәл** — сила, мощь, бодрость
**хәл ит** — реши, улад
**хәл фигыль** — деепричастие
**хәтле** — до, по
**хәтта** — даже, вплоть

## Һ

**һаман** — постоянно
**һәйкәл** — памятник
**һәлак булу** — погибнуть
**һәлакәт** — крушение, гибель, бедствие
**һәрбер** — каждый
**һәрвакыт** — всегда, постоянно
**һәркайсы** — каждый, любой
**һәркем** — каждый (человек)
**һәр көн** — каждый день
**һичшиксез** — без сомнения; обязательно
**һөнәр** — профессия, ремесло

## Ч

**чаклы** — до
**чакыр** — зови
**чат** — перекрёсток
**чәч** — волос
**чебен** — муха
**чирлә** — болей
**чит ил** — чужая, зарубежная страна
**читләш** — отдаляйся
**чишмә** — родник
**чүлмәк** — горшок
**чыгыш** — выступление

**чыда** — терпи
**чынлап** — в самом деле
**чын күңелдән** — от всей души
**чынык** — закаляйся

# Ш

**шаккат** — удивляйся, поражайся
**шарт** — условие
**шартлавык** — смолёвка
**шартнамә** — договор
**шәп** — здорово, хорошо
**шәфкатьле** — милосердный
**шоп-шома** — гладкий-прегладкий
**шу** — катайся
**шул** — тот
**шулаймыни** — неужели
**шулкадәр** — так, до такой степени
**шулпа** — бульон
**шунда** — там
**шуыш** — ползай

# Ы

**ылыс** — хвоя
**ыңгыраш** — стони
**ыргыт** — бросай
**ышан** — верь, поверь
**ышанычлы** — верно, верный; надёжный

# Э

**эз** — след
**эзлә** — ищи
**эл** — повесь
**эләк** — ловись, попадись
**элгеч** — вешалка
**элек** — раньше
**элемтәче** — связной, связист
**энә** — иголка
**эндәш** — обращайся, зови
**эссе** — жарко; жаркий
**эч** — живот
**эчке** — внутренний
**эшлекле** — деловой
**эшмәкәр** — бизнесмен, предприниматель

# Ю

**юан** — толстый, полный
**юаш** — смирный, тихий, кроткий
**югал** — исчезни
**югалт** — теряй
**юеш** — мокро, мокрый; сыро, сырой
**юка** — тонко; тонкий
**юкә** — липа
**юкка** — напрасно, понапрасну, зря
**юклык** — отсутствие, неимение
**юлдаш** — спутник, попутчик
**юлчы** — путник, проезжий, странник
**юмарт** — щедрый
**юньле** — толковый, умный
**юрган** — одеяло (стёганое)
**юри** — умышленно, нарочно
**ютәл** — кашель
**юын** — умывайся

# Я

**ябык** — худой; закрытый
**ябыш** — цепляйся, приклеивайся
**ябыштыр** — заклей

**ягулык** — горючее
**ягымлы** — ласково; ласковый
**язмыш** — судьба
**якла** — защищай
**якташ** — земляк
**якынлаш** — приближайся
**яланаяк** — босиком
**ялангач** — голый
**ялганла** — лги, ври
**ялгыз** — одинокий
**ялгыш** — ошибка; ошибочный
**ялкын** — пламя
**ялтыра** — блести
**ямьле** — красиво, красивый;
уютно, уютный
**ян** — гори
**яңгыра** — греми, звучи
**яра** — рана
**ярат** — люби
**ярты** — половина
**ярыйсы** — удовлетворительный,
средний
**яса** — делай
**ятим** — сирота
**ятла** — выучи
**яшен** — молния
**яшер** — прячь
**яшерен** — тайный
**яшьтән** — смолоду

# Эчтәлек

**Белем һәм тормыш**

1–24 нче дәресләр ....................................................3

**Мин һәм минем яшьтәшләрем**

25–37 нче дәресләр ....................................................32

**Буш вакыт**

38–54 нче дәресләр ....................................................47

**Өлкәннәр һәм кечкенәләр**

55–71 нче дәресләр ....................................................65

**Туган ягым табигате**

72–85 нче дәресләр ....................................................83

**Башкалабыз Казан**

86–102 нче дәресләр ....................................................99

**Сүзлек** ....................................................115

Учебное издание

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Малафеева** Рамиля Лябибовна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**7 класс**

Учебник для образовательных организаций
основного общего образования

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р. З. Хайдарова,*
*Р. Л. Малафеева, Г. М Ахметзянова*
Руководитель проекта *А. Т. Низамеева*
Художественный редактор *С. В. Киатров*
Руководитель группы художников и верстальщиков *Д. И. Бариев*
Вёрстка *Е. Б. Шараповой*
Координатор проекта *А. М. Ганиев*
Технический руководитель *И. М. Низаметдинов*
Редакторы *Ф. Ш. Ахметзянова, Г. М. Ахметзянова, И. А. Закиев*
Художники *А. Е. Гаранина, П. К. Михайлова, А. Я. Смольская,*
*Н. К. Авдеева, Г. И. Гилазетдинова, А. Р. Ромашова*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 10.08.2025. Формат 84x108$^{1}/_{16}$ . Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 6. Тираж экз. Заказ .

Издательство «Татармультфильм».
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2.
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
издательством «Татармультфильм» материалов в типографии

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,
— электронные учебники,
— мультимедийные пособия,
— методические пособия,
— рабочие тетради,
— художественно-анимационные издания,
— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте
**www.balarf.ru (www.бала.рф).**

# Имя действия
# Исем фигыль

**Имя действия — это форма глагола, которая имеет признаки глагола и имени существительного. Как и глагол, имя действия обозначает процесс, может иметь отрицательную форму. Как и имя существительное, оно обозначает это действие отдельно от действующего лица, изменяется по числам, падежам и может принимать аффиксы принадлежности.**

| | | |
|---|---|---|
| **Б.к.** | авырт(-ма)-у | йөр(-мә)-ү |
| **И.к.** | авырт(-ма)-у-ның | йөр(-мә)-ү-нең |
| **Ю.к.** | авырт(-ма)-у-га | йөр(-мә)-ү-гә |
| **Т.к.** | авырт(-ма)-у-ны | йөр(-мә)-ү-не |
| **Ч.к.** | авырт(-ма)-у-дан | йөр(-мә)-ү-дән |
| **У.-в.к.** | авырт(-ма)-у-да | йөр(-мә)-ү-дә |

# Повелительное наклонение
# Боерык фигыль

**Глаголы в повелительном наклонении (боерык фигыль) выражают просьбу, повеление, приказ совершить какое-то действие и имеют формы 2 и 3 лица единственного и множественного числа.**

| Положительная форма. Барлык формасы | | |
|---|---|---|
| лицо | единственное число | множественное число |
| 1 | — | — |
| 2 | (син) бар — (ты) иди | (сез) бар-ыгыз — (вы) идите |
| 3 | (ул) бар-сын — (он, она) пусть идёт | (алар) бар-сын-нар — (они) пусть идут |

| Отрицательная форма. Юклык формасы | | |
|---|---|---|
| лицо | единственное число | множественное число |
| 1 | — | — |
| 2 | (син) бар-ма — (ты) не иди | (сез) бар-ма-гыз — (вы) не идите |
| 3 | (ул) бар-ма-сын — пусть (он, она) не идёт | (алар) бар-ма-сын-нар — (они) пусть не идут |

ФГОС



ISBN 978-5-906508-55-3

издательство
«Татармультфильм»